Смартфонда уку өчен тәгаенләнгән QR-кодын кабызыгыз һәм фотокамераны әлеге билгегә төбәгез.

12+

## Иске документларны ничә ел сакларга?

Белгечләр әйтүенчә, милеккә кагылышлы документларны, паспорт, туу, үлем, никах турында таныклыкларны, ИНН, медицина һәм пенсия страховкалары карточкаларын “мәңге саклагыз».

Банк ипотекасы яисә башка займны түләп бетергәч бирелә торган белешмәне дә ташламагыз, чөнки сораулар туарга мөмкин.

Торак-коммуналь хезмәтләргә түләү турындагы квитанцияләрне өч ел, товарларга чекларны ике атна дәвамында саклагыз. Ә электроника сатып алуга килешүләрне ким дигәндә өч ел яисә гарантия срогы тәмамланганчы сакларга кирәк.


Башкортстан яшьләре гәзите

Сатуда бәясе ирекле

# Өмет

17 МАРТ, ЖОМГА, 2023 ел, № 11 (3796)

1991 елның 12 июленнән чыга

Гәзит жомга көнне чыга. Электрон адрес: Omet-ufa@mail.ru

Безнең сайтлар: https://omet-rb.com/ https://ok.ru/ometrb



podpiska.pochta.ru


# Ирекмәннәр иренмәгән халык

Бүздәк районында М.Шәйморатов исемендәге Волонтерлар (ирекмәннәр) штабы булдырылган. Аның максаты мобилизацияләнгән һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларның үзләренә һәм аларның гаиләләренә социаль, психологик, көнкүреш ярдәме күрсәтү.



Надежда Карамышева, Альбина Янбухтина, Диана Имашева.

7 бит

## Бу санда...


3 бит — Ямаулык өстенә ямаулыкмы?



10 бит — Рамазан – догалар ае



11-14 бит — Чаткылар




*Гәзиткә кул куйганда...*

## 235 мең сум бурычы җыелган


**Бу атнада Уфа урамнарының берсендә дәүләт автоинспекторлары Mitsubishi Lancer автомобилен туктата. Руль артындагы 39 яшьлек водительнең документларын тикшергәч, мәгълүматлар базасында аның 235 мең бурычы барлыгы ачыкланган. Шулардың 33 меңе – юл кагыйдәләрен бозган өчен.**

“Тиешле документларны рәсмиләштергәннән соң, суд приставлары федераль хезмәте ирнең машинасын махсуслаштырылган стоянкага урнаштырган”, — диләр дәүләт автоинспекциясендә һәм бурычлыларны ачыклау буенча уртак эш дәвам итүен әйтеләр.

Административ хокук бозулар турындагы кодекска ярашлы, җаваплылыкка тарттырылган кеше карар үз көченә кергәннән алып 60 көн эчендә штрафны түләргә тиеш. Штрафлар турындагы мәгълүматны дәүләт автоинспекциясенең рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәтләре порталында белеп була.

**Ә. ШАКИРҖАНОВА.**

## Һава торышы




*Башкортстанның кайбер районнарында 11 градуска кадәр җылытмакчы булып тора.*

*17 мартта көндез һава температурасы 9 градуска, кайбер районнарда 11 градуска кадәр җылытачак. Җил көньяк һәм көньяк-көнбатыш юнәлешләрдә исәчәк.*

*18 мартта, шулай ук, явым-төшем булмаячак. Төнлә температура -1...-6 градус, көндез 3-7 градуска кадәр җылы булачак.*

*19 мартта һава температурасы бераз түбәнәячәк. Төнлә -5, -6, көндез +4 градус булачак.*



# Интернет
## ЧЕЛТӘРЕННӘН

•Илче Олег Озеров белдерүенчә, АКШ белән Евросоюз илләре, Русия белән хезмәттәшлек итүен туктатуны таләп итеп, Африкага яный башлаган.

•Антарктидадан 1550 квадрат чакрым тәшкил иткән боз кисәге аерылып йөзеп киткән.

•Мәскәү эшкуарлары властьлар ярдәмендә Латин Америкасы илләренә товарларын чыгаруны арттыра башлаган.

•2022 елда Әрмәнстанга Русиядән 110 мең кеше күченеп барган, бу илнең икътисадын 3 процентка үстерергә ярдәм иткән.

•Әрмәнстанның икътисад министры Ваган Керобян әйтүенчә, Мәскәү белән Ереван, доллар белән евродан тулысынча баш тартып, милли валюталарда исәп-хисап ясый башлаганнар.

•Былтыр Грузиягә — 112, Казахстанга 200 меңләп русиялe яшәргә күчкән.

•2021 елда Оренбург өлкәсендә Башкортстаннан укырга барган өч кызны көчләп, аннан ерткычларча үтергән 29 яшьлек ирне гомерлеккә ирегеннән мәхрүм иткәннәр.

•Метеорологлар Башкортстанда язгы ташкын, боз китү 7-18 апрельгә туры киләчәк, дигәннәр.

•Башкортстанда каты көнкүреш калдыкларын эшкәртү өчен 9,5 миллиард сумга объектлар төзү планлаштырыла.

•Уфа шәһәре кызы 26 яшьлек Анна Быкова "Мисс-Европа-2023" халыкара конкурсында өченче урын алган.

•Югары категорияле табиб-онколог, медицина фәннәре докторы, профессор Александр Серяков яман шеш китереп чыгаручы төп продуктны атаган. Аның фикеренчә, ысланган азык-төлек (колбаса, сарделька, сосиска) организмда яман шеш китереп чыгару ихтималлыгын 18 процентка арттыра.

•Сиднейда бер драйвер, ике ел элек диңгез төбендә югалган йөзекне эзләп, акулалар арасында алты сәгать үткәргән. Нәтиҗәдә йөзекне тапкан.

# Юл буенда дүрт яңа төзеләчәк

**Башкортстанда гомум бәясе 100 млн. сумнан артыграк булган юл буендагы комплекслар барлыкка киләчәк. Яңа комплекслар Чишмә районы территориясендә урнашачак.**

"Проектларның берсе М5 федераль автомобиль юлында барлыкка киләчәк. Ул үз эченә парковка, автосервис, кафе, машиналар юуны һәм сәүдә комплексын алачак. Инвестицияләрнең күләме якынча 52 млн. сум тәшкил итәчәк. 26 яңа эш урыны булачак.



Икенче инвестор ике объект төзелешенә 50 млн. сумга кадәр акча кертергә планлаштыра. Аларда кунакханә, туклану пункты, автосервис һәм автозаправка станциясе булачак. Тагын бер комплекс — ул 6 млн. сумлык Кара Якуп авылында ачылачак", — дигән Андрей Наза-

# Башкортстанда 18 миллиардер бар

**Башкортстанның салым инспекциясе хезмәте республикада 18 кешенең кереме 1 миллиард сумнан артык булуы турында хәбәр итә.**

2022 ел өчен салым декларациялрен тапшырганнан соң, үткән елда иң зур керемнең 7,86 миллиард сум акча эшләгән кешедә булуы ачыкланган. Бу кереме ул чит ил компаниясе эшчәнлегендә катнашу нәтиҗәсендә алган. Гомумән алганда, 2022 елда Башкортстанда физик шәхесләрнең керемгә салымы буенча барлыгы 486



мең декларация тапшырылган. Бу 2021 ел белән чагыштырганда 4,1 %ка күбрәк.

# Мәскәүлеләр спорт ярата




**Мәскәү авылы икенче ел рәттән «Аек авыл» республика конкурсында катнаша. Күптән түгел әлеге республика конкурсы кысаларында узган йомгаклау чарасы "Мәскәү спорт өчен!" киң күләмле флешмоб белән башланды.**

Шулай ук обелискка чәчәкләр салу тантанасы узды. Мәскәү урта мәктәбенең спорт залында җиде тапкыр дөнья чемпионы, халыкара шашка буенча ике тапкыр Европа чемпионы, Башкортстан Республикасы шашка федерациясе башкарма комитеты рәисе Тамара Тансыккужина белән шашка турниры үтте. Турнирда күрше Бөре шәһәреннән һәм Чакмагыш районыннан спортчылар катнашты.

Пима киеп хоккей уйнау да иң мавыктыргыч булды. Анда Имай-Утар авылы командасы җиңү яуласа , Мәскәүлеләр белән Бөре районының Кузов авылы хоккейчылары икенче-өченче урыннарны бүлеште.

Авыл мәдәният йортында "Шоңкар" театр коллективы Айгөл Әхмәтгалиеваның "Баш куям тезләреңә" пьесасы буенча куелган спектакль күрсәтте.



# Аккошлар кайткан

**Куергазы районының Ермолаево авылында безнең якларга кайтучы беренче аккошларны күргәннәр.**

"Алар быел да Шоттов паркына төшкәннәр", — дип хәбәр итәләр Куергазыдан. Урындагы халык аларны сагынып каршы алган, кошларны ипи белән сыйлаганнар. Парктагы күл әле эреп тә бетмәгән, әмма бу горур, матур кошларга комачаулык тудырмый.



# Депутатка повестка килгән

**Русия гимнын башкарганда торып басмаганы өчен Калуга өлкәсенең Кече Ярославец районы җыелышы депутаты Александр Лепендинны тәнкыйть утына тотканнар иде. Күптән түгел депутатка хәрби комиссариатка чакыру кәгазе килгән.**

Лепендинны хәрби комиссариатка аның турындагы мәгълүматларны тикшерер өчен чакырганнар, диләр. Чакыру кәгазен аңа депутат этикасы буенча комиссиядә тапшырганнар. Бу комиссия аның әлеге кылыгын тикшергән. Депутат гимн яңгыраганда торып басмавын тренировкадан соң аруы белән аңлаткан. Хәлем бетү сәбәпле тора алмадым, дип акланган. Лепендинның коллегалары аның аклануларын ахмакларча кылану дип атаганнар.

Э.ӘСӘДУЛЛИНА, И.НИГЪМӘТУЛЛИНА, Р.ТАҖИЕВА әзерләде.

podpiska.pochta.ru

**КЫШЫН ЧОКЫР-ЧАКЫРЛАР БИК СИЗЕЛМИ, ӘММА, КАР ЭРЕГӘННӘН СОҢ, КАЙСЫБЕР ЮЛЛАРДА ЧЫН МӘХШӘР БАШЛАНА. ЧОКЫРЛАРДАН ҮТКӘН САЕН ВОДИТЕЛЬЛӘРНЕҢ БАРЫСЫ ДА БУЛМАСА ДА, ИКЕСЕНЕҢ БЕРСЕ АҺ-ЗАРЫН “МАТУР СҮЗЛӘРЕ” БЕЛӘН БЕЛДЕРМИ КАЛМЫЙДЫР. АҢЛАРГА ДА БУЛА ИНДЕ ҮЗЛӘРЕН: ШАКТЫЙ ЗУР СУММАГА КРЕДИТКА АЛГАН АВТОМОБИЛЕҢНЕ ҺИЧ КЕНӘ ДӘ, НАЧАР ЮЛЛАРДА ЙӨРЕП, САФТАН ЧЫГАРАСЫ КИЛМИ ШУЛ…**



# Ямаулык өстенә ямаулыкмы?

## Яз җиткәч, каргалар кайта, умырзаялар чәчәк ата һәм асфальт юлларда чокырлар арта…

Быел да, юллар кардан ачылуга водительләрдән чокыр проблемасы турында зарлар агыла башлады, диләр республиканың Дәүләт автоинспекциясендә.

“Яз җиткәч, гадәттә, төнге һәм көндезге температуралар кинәт үзгәреп тора башлый. Шул сәбәпле, юлларда һәм урамнарда машиналар йөри торган урыннарда чокырлар, юл катламында башка кимчелекләр барлыкка килә. Узган бер тәүлектә генә юллардагы чокырлар аркасында водительләр үзләренең автомобильләренә зыян китергән 20 очрак теркәлде”, — дип язган иде 11 мартта республиканың баш автоинспекторы Владимир Севастьянов.

Аның әйтүенчә, башкаланың юл күзәтчелеге хезмәткәрләре рейдларга чыгып тора. Шулай ук автоинспекторлар да язын даими рәвештә урамның юл челтәрен тикшерә. Кимчелекләр ачыкланса, җаваплы кешеләргә хәбәр ителә. Юл кемнең балансына карый, шул кимчелекләрне бетерергә тиеш. Таләпләр үтәлмәсә, мәгълүмат прокуратурага җибәрелә.

Әйе, Русия юлларында чокырлар — мәңгелек проблема. Аны кайчан хәл итерләр һәм, гомумән, итә алырлармы — бу сорауга бүген җавап бирүче табылмас, мөгаен. Ә бит һәр автомбиль хуҗасы дәүләткә транспорт салымы түли. Дәүләт бу акчаларны юлларны тәртиптә тотуга тотынырга тиеш. Чөнки юллардагы кимчелекләр җитди һәлакәтләр сәбәпчесе булырга мөмкин.

ГОСТка ярашлы, юлдагы чокырның хәрәкәт юнәлеше буенча озынлыгы — 15 сантиметрдан, тирәнлеге — 5 сантиметрдан, гомум мәйданы 0,06 квадрат метрдан артмаска тиеш. Әгәр водитель яки автомобиле шуннан зуррак чокырда зыян күрсә, ул әлеге юлга хезмәт күрсәтүче юл оешмасыннан суд аша компенсация түләттерүгә ирешә ала. Моның өчен чокыр аркасында зыян күрүне, чокырның күләмен фотога төшереп алырга кирәк. Юл-транспорт һәлакәтен рәсмиләштерү өчен полиция хезмәткәрләрен чакыртсагыз тагын да яхшы, диләр экспертлар.

Әлбәттә, юлда күпләребез ашыга һәм, туктап, чокыр үлчәп йөрүчеләр бик аздыр, мөгаен.

Шунысын да әйтергә кирәк: ул чокырларны ел саен ямыйлар ямавын. Әмма чокыр ремонты — юлларда аварияләрне киметү максатыннан башкарылган вакытлыча һәм мәҗбүри чара, ул юлны капиталь төзекләндерүне алыштыра алмый. Ә юлларны тулысынча ремонтлау көннәр җылынгач башлана. Ләкин бер җәйдә бар юлларны да ремонтлау мөмкин түгел. Шуңа быел ямалып кына калган чокырларның күбесе алдагы елга, гадәттә, тагын да зуррак чокырга әйләнә, ямаулык шулай ел саен зурайганнан зурая.

Бүген чокырлар салкынча һәм температура сикерүе шартларында эшләү мөмкинлеге биргән катнашма белән ямала. Чималга килгәндә, соңгы елларда аның сыйфаты күп сораулар тудыра. Быел ремонтлаган зур юлда икенче елга ук чокырлар барлыкка килү, әйтик, башкаланы бизи торган хәл түгел. Ни дисәң дә, юллар — һәр шәһәр, авылның йөзе. Уфага керүчеләрне каршы алучы Салават Юлаев проспектында исә быел, чокырларга эләгеп, машина тәгәрмәчләрен тишүчеләр саны көн саен арта бара. Моны Уфа мэры Ратмир Мәүлиевның Вконтакте сәхифәсендә калдырылган язмалардан да күреп була.

Чокыр-чакырлар тиздән ямалыр дип ышанасы килә. Ә әлегә, Владимир Севастьянов әйтүенчә, язгы юлда водительләргә күлләвекләр аша үткәндә тизлекне киметергә һәм кискен хәрәкәтләр ясамаска кирәк.

### Аяк асты боз гына

Бу көннәрдә җәяүлеләрдән дә зарлар арта. Көндез эретеп, төнен туңдырганнан соң юллар бозлавыкка әверелә. Уфада урыны белән үзеңне тимераякта йөргәндәй хис итәсең. Кичә күрше апа зарланып торды. “Тротуарларга ниндидер реагент сибәләр. Ул башта эри, аннары аның астында боз барлыкка килә. Йөрерлек түгел. Балалар белән бакчага чак барып җитәбез. Бүген күз алдында ике хатын таеп егылды. Берсе башы белән машинага барып бәрелде”, — дип бәян итте ул.

Чынлап та, бүген травмпунктларга мөрәҗәгать итүчеләр саны күбәя. Табиблар әйтүенчә, күбесенең аягы яки кулы сынган, умыртка баганасына зыян килгән була. Шуңа егылганда да хәвефсезлек техникасын белергә кирәк, ди башкаланың 17нче санлы балалар клиник дәваханәсенең травматолог-ортопеды Ринат Хәйруллин.

“Мондый вакытта тәү чиратта хәвефсезлек чараларын истән чыгармаска кирәк. Табаны таймый торган аяк киеме кияргә тырышыгыз. Андый булмаса — набойка куйдыртырга була. Акрынрак атлагыз. Егылганда да дөрес егылырга кирәк”, — ди ул.

Әлбәттә, аягың таеп китсә, ничек дөрес егылыйм икән дип уйлап өлгермәвең дә бар. Шулай да белгечләрнең киңәшләрен мыек очына чорнап кую артык булмас, мөгаен.

Беренчедән, егыла башлауны сизүгә, тиз арада утырырга тырышырга кирәк. Чөнки бөтен гәүдә белән егылуга караганда, утырган очракта җәрәхәт алу куркынычы азрак. Шуңа утыру һәм тору (приседание) күнегүен еш ясарга киңәш ителә, шул чакта буыннар әлеге күнегүне “истә калдыра”.

Икенчедән, егылганда иң куркынычсызы — эмбрион позасына керү. Монда муен — иңбашына, ияк — күкрәккә, терсәкләр гәүдәгә таба “җыела”. Шул ук вакытта тезне бөгеп өлгерергә дә кирәк.

Өченчедән, сөяк сынудан саклану максатыннан тәнне йомшартырга түгел, киресенчә, бераз катырып куярга кирәк. Гәүдә “катырылмаган” булса, төп көч сөяккә төшеп, аны сындырырга мөмкин. Ә бәрелү, тукымалар зарарлану сөяк сынуга караганда тизрәк төзәлә.

Һәм соңгысы: умыртка баганасына зыян килмәсен өчен ян белән егылырга тырышыгыз. Кышын кул сындыру очраклары күп була. Бу рефлектор рәвештә кулны алга сузып, бөтен гәүдә белән егылуга бәйле, диләр.

Әлеге кагыйдәләрне истә тотып, исән-имин кара туфракка аяк басарга насыйп булсын!

**Язгөл САФИНА.**



# Махсус операциядәгеләргә сүз тидермәгез!

## Югыйсә төрмә яисә штраф янавы бар

**Дәүләт Думасы өченче укуда махсус операциядә катнашучыларны дискредитацияләгән һәм алар турында ялган тараткан өчен җинаять җаваплылыгы турындагы закон проектын кабул итте. Хокук бозучыларга 15 елга кадәр иректән мәхрүм итү яный.**

Төзәтмәләр Русия Кораллы көчләрен чит илдә куллануны дискредитацияләгән өчен җәзаны катгыйлата. Төзәтмәләр үз теләкләре белән махсус хәрби операциядә катнашучыларны дискредитацияләгән өчен җаваплылык кертеп кенә калмый, гомумән бу маддә буенча җәзаның срогын җиде елга кадәр арттыра да.

Моннан тыш, төзәтмәләр Кораллы көчләр турында ялган тарату өчен җаваплылык турындагы җайга салган маддәгә дә кертелә. Хәзер ирекле формированиеләргә каршы кылынган җинаятьләр очрагында фейклар тараткан өчен дә җәза булачак. Бу маддә буенча иң югары җәза — 15 елга кадәр иректән мәхрүм ителү.

Шулай ук үз теләкләре белән махсус операциядә катнашучыларны дискредитацияләгән өчен (әгәр моның өчен җинаять җәзасы каралмаса) Административ хокук бозулар турындагы кодекска штрафлар турында төзәтмәләр кертелде. Гражданнар өчен штраф — 30дан алып 50 мең сумга кадәр, вазифа биләүчеләр өчен — 100дән алып 200 мең сумга кадәр, юридик шәхесләр өчен 300дән алып 500 мең сумга кадәр тәшкил итәчәк.

podpiska.pochta.ru



# Язгы бозга ышанма!

## Үзебез дә сак булыйк, башкаларны да кисәтик

**Табигатьне уятучы, күңелләрне ашкынулы хисләргә чорнаучы язны барыбыз да көтеп ала. Әмма елның бу фасылы шатлык кына түгел, өстәмә мәшәкатьләр дә, иң аянычы – кайвакыт кайгы-хәсрәтләр дә алып килергә мөмкин. Юкка гына “язгы бозга, ястык калынлыгында булса да, ышанма” димиләр шул. Елга-күлләр өстендәге боз катламы үзенең ныклыгын югалта бара. Ни аяныч, балыкчылар да, кышын боз өстендәге сукмактан йөрергә күнеккән кешеләр дә язгы бозның никадәр куркыныч тудыруы турында онытып җибәрәләр. Нәтиҗә буларак, боз астына төшеп китү очраклары арта.**

### Кашкадан суында – ир-ат гәүдәсе

Быел да шундый хәлләр булды. Соңгыларыннан — дүшәмбе көнне, 13 мартта, Уфаның Кашкадан күлендә 62 яшьлек ир-ат, боз астына китеп, чыга алмый үлгән. Башкаланың гражданнарны яклау идарәсенең матбугат хезмәтендә хәбәр итүләренчә, 13 мартта 20.25 сәгатьтә Уфаның дежур диспетчерлык хезмәтенә бер ир-ат шалтыратып, Кашкадан күле тирәли ял итеп йөргән вакытында суда кеше барлыгын шәйләве турында хәбәр иткән. Гидрокостюмлы коткаручылар суга чумып, тынсыз гәүдәне табып алганнар. Иргә ярдәм күрсәтергә тырышып караганнар, әмма ул бу дөнья белән хушлашырга өлгергән була.

Бу хәлнең очраклы шаһиты булган берәү фаҗигане видеога төшереп, социаль челтәрләргә дә куйган. Видеодан күренүенчә, коткаручы-водолазлар ирнең су астыннан табылган, капчыкка салынган гәүдәсен машинага салалар... Иркәй төнгә каршы күл өстендә нишләп йөргән? Нинди сәбәпләр аны сулыкка алып килгән? Монысын тикшерүчеләр ачыклар.

Үткән елның ноябрендә, сулыкларда боз ныклап туңып өлгермәгән вакытта, Федоровка районының Ключевка авылында 8 яшьлек баланың гәүдәсе табылуы турында хәтерлисездер. Малай белән апасы ярдан 15 метр эчтәрәк боз өстендә уйнаганнар. Кайсыдыр бер мизгелдә, күз ачып йомганчы, боз чатнап, малай салкын суга чумган. Апасының аны коткарырга көче дә, осталыгы да җитмәгәндер инде. Нәтиҗәдә, ул ярдәм сорап әти-әнисенә йөгерә. Тик зурлар килеп җиткәндә соң була инде.

### “Сез җавапсыз!” диясе килә

Елга-күлләрдә бозның җитәрлек дәрәҗәдә калын булуына инанмый торып, балык тотарга яисә бозда шуарга ашкынган кешеләргә: “Сез җавапсыз!” — диясе килә. Республиканың Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәгълүматлары буенча, үткән елның көзендә — кыш әле ныклап башланмаган мәлдә! — берничә көн эчендә су астына китүнең берничә очрагы теркәлгән: Сибайда — Балыкчы йорты күлендә 1958 елгы ир, Дәүләкәндә Дим елгасында ярдан 25 метр эчтәрәк бер ир боз астына киткән. Бәхеткә, соңгысын очраклы кешеләр коткара алганнар. Белоретта боз астына киткән ВАЗ 2121 автомобилен тапканнар. Ничә көннәр яткандыр ул су астында — билгесез. Водолазлар машинаны тикшергәннәр, эчендә үле гәүдәләр табылмаган.

Кешеләр генә түгел, этләрнең дә, атларның да боз астына китү очраклары еш күзәтелә. Мәсәлән, шушы көннәрдә социаль челтәрләрдә Мәләвез шәһәрендә яшәүче Рөстәм исемле ир-атның, Мәләвез елгасында боз ватылып, салкын суга чумган этне коткаруын сурәтләгән видеоролик пәйда булды. “Ничек анда төшкән ул? Муенчагы бармы? Эләктер шуннан! Ипле кылан, үзең төшеп китмә!” — дүрт аяклы дусны бозлы судан коткару операциясен мобиль телефонының камерасына төшереп торучы хатын-кыз тавышы шулай ди. Тагын да бераздан иркәй шыңшыган этне коткаруга ирешә. Тегесе, коткаручыга рәхмәтле карашлар ташлый-ташлый, каядыр ашыгуын белә.

Этләр дә, атлар да дигәннән, моннан ике ел элек февраль аенда Иглин районында күпләп ат үрчетүче фермер, кызганычка каршы, шушы көннәрдә мәрхүм булган Хәсән Сәгыйтҗан улы Идиятуллинның 11 аты боз астына китеп, чак һәлак булмый калуы турында күпләр ишеткән булгандыр. Коткару операциясен үз вакытында башламасалар, малкайларның гомере өзелер иде бит.

Яз көне боз өстеннән йөрүнең куркыныч булуы турында һәрберебез истә тотарга тиеш. Әгәр сулык аша чыгарга туры килсә, куелган билгеләргә игътибар итәргә, боз өстенә салынган махсус басмалардан файдаланырга тиешбез. Күп кеше биек яр буеннан боз киткәнен карарга ярата. Әлбәттә, күңелле, ләкин кайвакыт су агымы яр кырыйларын ашый һәм ул көтмәгәндә ишелеп төшәргә мөмкин. Мондый урыннарда бик сак булыгыз!

Бигрәк тә балалар язын су буйларында уйнарга ярата һәм бәхетсезлек очраклары күбрәк алар белән килеп чыга. Елга, күл буйларында уйнап, аккан боз өстенә дә кереп китәләр.

Бәхетсезлек очракларын булдырмау максатыннан әти-әниләр, укытучылар балалар алдында аңлату эшләре алып барырга, язгы бозның никадәр куркыныч булуы турында кисәтеп куярга тиеш.

Бәхетсезлек очракларын урап узу максатыннан түбәндәге мәгълүматлар белән танышу файдалы булыр. Шулай итеп, әгәр...

### ...язгы суга батучыны күрсәгез:

*баткан кеше янына бик сак шуышып килегез;

*“ярдәмгә киләм!” дип кат-кат кычкырыгыз — батучыга сезнең сүзләр көч, өмет өстәр;

*3-4 метр кала янызгызда нәрсә бар — билбау, шарф, таяк, такта — шуларны батучыга сузыгыз:

*Каза күрүчегә кул сузу хәвефле, чөнки батучыга якын килеп, бозга көчәнеште арттырып кына калмыйсыз, үзегез дә бозлы суга төшеп китәргә мөмкинсез;

### Әгәр боз ватылып, салкын суга чумсаң, нишләргә?

*паникага бирелмәскә, кычкырып ярдәм чакырырга;

*чәбәләнмәскә һәм гәүдәнең бар авырлыгы белән боз читенә ятмаска — юка боз ватылачак кына;

*баш белән су астына китмәс өчен кулларны киң итеп җәяргә тырышырга;

*терсәкләр белән боз читенә таянып, гәүдәне горизонталь хәлгә китерергә, шулай иткән хәлдә юеш җиңнәр бозга ябышып катар һәм аңны югалткан хәлдә дә су өстендә калырга мөмкинлек бирер;

*ярдәм көткән вакытта судан үзаллы чыгарга тырышудан туктамагыз: юешләнеп авырайган киемнәрне салырга тырышырга кирәк. Аска табан сөйрәүче киемнәрдән арынсагыз, боз өстенә үрмәләп чыгуы җиңелрәк булыр.

*Болай итәргә дә була: боз читен кулларыгыз белән вата-вата якындагы ярга таба хәрәкәт итегез. Бозны вата алмый башлауга, кулларыгызны мөмкин кадәр ераграк сузып, боз өстенә ятарга һәм талпынып, чыгарга тырышыгыз. Бу вакытта аякларыгыз белән кискен хәрәкәтләр ясап, гәүдәгезгне горизонталь хәлдә тотарга омтылыгыз;

*боз өстенә чыккач та, торырга ашыкмагыз, кулларны җәеп, сузылып яткан хәлдә, алга таба шуышыгыз гына;

*бозның ныгыганын сизгәч кенә, ян-якка борылып, ярга таба тәгәрәп барырга кирәк;

*ярга чыгуга, хәрәкәтләнүдән туктап калмагыз.

Бозлы суга баткан кешене коткарган кеше арытаба нишләргә тиеш? Иң беренче чиратта, батучыны җылсез, хәвефсез урынга күчерергә, кул астында булган коры киемнәр кидерергә яисә одеялга төрергә онытмагыз. Әгәр ул үз аңында булса, кайнар чәй яисә кофе бирергә киңәш ителә. Аңында булмаса, тиз арада дәваханәгә илтеп җиткерү чарасын күрергә кирәк.

*Онытмагыз! Бозлы суда өшегән тәнне ышкырга, батучыга спиртлы эчемлекләр бирергә ярамый — болай организмга зыян гына китерергә була.*

Язгы суга чумган кешенең, иң беренче чиратта, тыны кысыла, башны тимер кыршау белән кыскан кебек була, йөрәк тибеше кискен ешая, артериаль кан басымы куркыныч чикләргә кадәр күтәрелә. Күкрәк читлеге һәм корсак мускуллары рефлектор рәвештә кыскара.

Балыкчыларга да киңәш бирәсе килә. Алар үзләре белән 25 метрдан да ким булмаган озынлыктагы ныклы бау алырга һәм ул кирәк вакытта тиз генә кулга алырлык урында торырга тиеш. Алмаш эчке кием алу да комачауламас.

Бары тик игътибарлы, сак, җаваплы булсак кына язгы сулыкларда бәла-казаларга юлыкмасбыз, гаиләбезгә кайгы-хәсрәт китер-мәсбез. Күп нәрсә үзебездән тора.

ЯЗГЫ СУГА ЧУМГАН КЕШЕНЕҢ, ИҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА, ТЫНЫ КЫСЫЛА, БАШНЫ ТИМЕР КЫРШАУ БЕЛӘН КЫСКАН КЕБЕК БУЛА, ЙӨРӘК ТИБЕШЕ КИСКЕН ЕШАЯ, АРТЕРИАЛЬ КАН БАСЫМЫ КУРКЫНЫЧ ЧИКЛӘРГӘ КАДӘР КҮТӘРЕЛӘ. КҮКРӘК ЧИТЛЕГЕ ҺӘМ КОРСАК МУСКУЛЛАРЫ РЕФЛЕКТОР РӘВЕШТӘ КЫСКАРА.

Руфина ТАҖИЕВА.

Бәйләнешләр




# Асад Мәскәүгә ник килде?

**Сүрия президенты Бәшәр Асад Мәскәүгә килде.** Русия президенты Владимир Путин белән өч сәгатькә сузылган әңгәмәдә геосәяси хәлләр торышы тикшерелде. Асад зур ярдәм күрсәткәне өчен Русиягә рәхмәтле булуын белдерде.

Ике ил җитәкчесе дә Сүрия белән Русия арасындагы дуслыкның ныклы булуын ассызыклады. Бу очрашу иң тәү чиратта, бөтен дөньяга Русиянең Сүриядәге йогынтысы кимемәвен күрсәтү булды.

Асад Украинада барган махсус операциягә карата фикерен белдерде: «Неонацистларга һәм иске нацистларга каршы махсус операцияне Сүрия яклавын белдерәсем килә. Мин иске һәм яңа нацистлар димен, чөнки Көнбатыш үзенең җирендә иске нацистларны элек ничек кабул итсә, бүген дә ул моны дәвам итә, ярдәм күрсәтә»,—диде. Ул бу сүзләрне «дуслык һәм тугрылык» йөзеннән генә түгел, ә чынлап, бүген дөньяның тотрыклануга ихтыяҗ кичерүен тоеп әйтүен белдерде.



Әлеге, очрашуның төп максатларының берсе — Владимир Путинның Бәшәр Асадны Төркия президенты Рәҗәп Эрдоган белән бәйләнешкә керүгә инандыру иде. Мәскәү былтыр декабрьдә аларның очрашуын оештырырга тырышты, әмма тормышка ашмады. Төркия — Сүрия мөнәсәбәтләрен көйләү мәсьәләсе һаман бер урында тапана. Дамаск Төркиянең Сүрия төньягыннан гаскәрләрен чыгаруын, Әнкарага лояль булган «террор төркеме» дип атаган кораллы оппозицияне яклавын туктатуын таләп итә. Сүрия бу таләпләрне даими яңгыратып тора. Моннан тыш, Асад Төркиядә үтәчәк президент сайлауларына кадәр, Эрдоганга сәяси козырьләр бирмәс өчен, аның белән очрашырга теләмәвен белдерә килде. Ә менә төрек властьларына сайлау алдыннан бу сөйләшү бик кирәк. Аннары, Сүрия—Төркия чигендәге вакыйгалар көйләнсә, бу Төркиядәге Сүрия качакларының өйләренә кайтуын тизләтер иде. Әнкара исә «сепаратистлар» һәм «террорчыларга» каршы Дамаск белән бергә каршы торырга кирәк дип тәкрарлый. Әнкара фикеренчә, Сүриядәге Көрд отрядлары Көрдистанның Эшчеләр партиясе белән элемтәдә тора.

Мәскәү исә көрд отрядларының Төркия-Сүрия чиген контрольдә тотуны Дамаскка тапшырса, бу ике ил арасындагы киеренкелекне бераз киметер иде, дип раслый. Тик әлегә Төркиянең Сүрия төньягын калдырып чыгарга исәбе юк.

**3 мең —**

**Казахстанда 2025 елга «идеологик картайган» шулкадәр шәһәр һәм урамнарның исемнәрен алыштырачаклар. Ә бүгенге көнгә 68 торак пункты һәм 572 урам исеме үзгәртелгән.**

## Әйткән сүз – аткан ук...



**Кушма Штатларның диңгез пехотасы разведка корпусының элеккеге Скотт РИТТЕР**: «АКШ Кушма Штатларның халыкара үсеш агентлыгы аша ел саен юнәлтелгән 40 млн. долларлык ярдәмне Грузиядәге бүгенге хөкүмәтне Грузиягә түгел, ә Америка максатларына һәм бурычларына хезмәт итәчәк яңасына алыштыру өчен файдалана. Бу исә Русиягә каршы «икенче фронт» булдыруны да үз эченә ала».

Провокация

# Кара диңгез өстендә очкан



**14 мартта Кара диңгез өстенә Американың пилотсыз очу аппараты килеп төште**. Русия Оборона министрлыгы Америка аппаратының Кара диңгезгә килеп төшүен раслады. Министрлык һавага күтәрелгән Русия истребительләренең пилотсыз очу аппараты белән контактка кермәве, корал кулланмавын белдерде. Оборона министрлыгы белдерүенчә, кинәт маневр ясый башлаган аппарат, идарәсен югалтып суга килеп төшкән.

Америка Русияне дронны алдан уйлап юк итүдә гаепләде. Очу аппараты халыкара һава киңлекләрендә көндәлек операцияне үткәрә иде, диде АКШның Европа һәм Африкадагы хәрби-һава көчләре командующие Джеймс Хеккер.

Ярамаган урында очмасын иде, диде Русия президентының матбугат-секретаре Дмитрий Песков вакыйгага аңлатма биргәндә. 15 мартта Русия оборона министры Сергей Шойгу Пентагон җитәкчесе Ллойд Остин белән телефон аша сөйләшкәндә Американың пилотсыз очу аппаратлары Кырым ярларында киеренкелек көчәйтү куркынычын арттыра дип белдерде.

Русиянең Вашингтондагы илчесе Анатолий Антонов вакыйганы провокация дип атады. Америка самолетлары һәм кораблары Русия чик буйларында маҗара эзләп йөрмәсеннәр, диде.

Протест

# Болгарлар нейтралитет яклы

**Болгария башкаласы София үзәгендә, Украина конфликтында үз илләренең тулы нейтралитет саклавын таләп итеп, йөзләрчә кеше акциягә чыккан.**



Акциядә катнашучылар НАТОга каршы язылган «Без туганнарыбызга атмыйбыз!», «Көнчыгыш фронты янәдән бездән башка» дигән лозунглар тотканнар. Моннан тыш, протест белдерүчеләр урамнарда алдагы елның 1 гыйнварыннан евроны әйләнешкә кертүгә каршы култамгалар җыйганнар.

Күптән түгел Болгарияне Украина конфликтына җәлеп итүгә каршы протест акциясендә 10 меңнән артык кеше катнашкан. Митинглар һәм урам демонстрацияләре София, Пловдив, Варна, Руса, Стара-Загора, Силистра, Казанлык, Шумен һәм Тырговиште калаларында үткән.

Соңгы ике елда Болгария өченче илләр аша Украинага миллиард долларлык корал озаткан. Урындагы компанияләр Украинадагы клиентлары белән турыдантуры түгел, ә чит ил компанияләре аша алыш-биреш ясый.

Кыскача гына

## Молдавия оборонасын ныгыта



**Европа Союзы Молдавиягә хәрби ярдәм пакеты бүләргә җыенган.** Молдавия бүленгән 40 млн. еврога, республиканың һава киңлекләрен контрольдә тоту өчен, ерак араны күзәтү радары алачак.

Акчаларның калган өлешен җиңел тактик транспорт чаралары һәм пикаплар, йөк төяү техникасы, автобус һәм йөк машиналары, коммуникация корылмалары сатып алуга юнәлтәчәкләр.

Акчаларны нигездә Украинада хәрби операция башланган вакыттан алып Киевка корал озатуда ярдәм итүче Европа тынычлык фонды бүлә. Фонд күләме 8 млрд евро тәшкил итә дип атала.

## Президентлык срогын арттырачаклар



**Үзбәкстанда президентлык срогын арттырырга җыенганнар.** Әлеге вакытта конституцион проектны әзерләү өстендә эшлиләр.

Депутатлар тәкъдименә ярашлы, президент бүгенге 5 ел урынына 7 елга сайланачак. Шулай ук закон проекты гамәлдәге президент Шәфкать Мирзиеёвның өченче тапкыр президент итеп сайлану ихтималлын да күзаллый.

Үзбәкстанда төп законны үзгәртү буенча референдум 30 апрельгә билгеләнгән.

Резеда КАДИКОВА әзерләде.

podpiska.pochta.ru



**БУЛДЫКЛЫ, ЗУР УҢЫШЛАРГА ИРЕШКӘН ЯКТАШЛАРЫ БЕЛӘН ҺӘРКЕМ ГОРУРЛАНА. АЛАРНЫ ТУГАН ЯГЫНЫҢ ЙӨЗЕК КАШЫНА ТИҢЛИЛӘР. АВЫЛДАШЫМ АЙРАТ ШӘЙХУЛЛА УЛЫ РАМАЗАНОВ – ЧЫН-ЧЫНЛАП КАЛМАШБАШНЫҢ ГЫНА ТҮГЕЛ, Ә ЧАКМАГЫШ РАЙОНЫНЫҢ, БАШКОРТСТАННЫҢ ДА ГОРУРЛЫГЫ.**

# Укытучы да, галим дә ул

Техник фәннәре докторы, БДУның (бүгенге Уфа фән һәм технологияләр университеты) физика-техник институтының геофизика кафедрасы профессоры, фәнни тикшеренүләр белән шөгыльләнеп зур дан-дәрәҗәләргә ирешкән, 200дән артык фәнни эш, уку әсбаплары, ике дистәдән артык патентлар һәм белешмәләр авторы ул Айрат абый Рамазанов. Ул шулай ук "СССРның уйлап табучысы" билгесенә, ВДНХның бронза медаленә, РФ Мәгариф министрлыгының Почет грамотасына лаек булган кеше. 2019 елда фәндә ирешкән уңышлары өчен БРның Фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт премиясе лауреаты булды. Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе.

Менә шундый биеклекләрне яулаган, ләкин авылыбызның иң хөрмәтле кешеләре булган әтисе Шәйхулла абый һәм әнисе Мөсаллия апа кебек үк гади һәм кечелекле, игътибарлы һәм ихтирамлы булып кала белгән Айрат абый белән җай гына әңгәмә корып утырабыз. Сораулар күп һәм төрле, Айрат абый аларның һәркайсын игътибар белән тыңлый.

**–Айрат абый, дөнья белән математика һәм физика фәннәре идарә итә диләр. Моның белән килешәсезме?**

— Мин шулай ук химия һәм биологияне дә өстәр идем. Алар бергәләп технологик үсешнең нигезен тәшкил итә. Әйтик, ясалма интеллект, нейрон-челтәрләр, чат-ботлар хәзер безнең өчен гадәти нәрсәгә әверелеп бара. Ә бит, бары моннан 10-20 ел элекке вакытка борылып карасак та, тормышның искиткеч тизлектә үзгәргәнен күрәбез. Кәрәзле телефонны гына алыйк. 90нчы елларда алар зур һәм бик кыйммәт тора иде, җитмәсә, бик сирәк урында "тота" иде. Бүген исә ул хәтта кечкенә балаларда да бар. Телефонда сыйфатлы фото һәм видео төшерү, боларны "хәтердә" саклау мөмкин. Җитмәсә әле, аларның "эчендә" Алиса, Сири кебек акыллы ярдәмчеләр утыра һәм безне аңлап, сорауларыбызга җавап бирәләр. Фантастика! Боларның барсы да фәннәрнең нык алга китүе, галимнәрнең зур тырышлыгы аркасында.

Ә алда безне ни көтә? Дистә еллар үтүгә галимнәр искиткеч акыл, ясалма интеллект уйлап табар дип уйлыйм. Алар кеше кебек үк уйлар, ләкин кешенең баш миенә караганда йөзләрчә-меңнәрчә тапкырга көчлерәк-тизрәк эшләр. Бүген галимнәр шуның турында бәхәсләшә: алар үзләре шул машиналар белән идарә итә алырлармы, әллә машиналар кешегә баш булып алырмы һәм "Җир шарына кешеләр нигә кирәк" димәсме? Әлегә җаваплар юк, ләкин, кызганычка каршы, тарих шуны дәлилли: яңа технологияләр кешеләргә тик яхшы нәрсәләр генә алып килми шул (мәсәлән, дары, атом-төш коралы һ.б.).

**– "Авыл мәктәбендә укып, ерак китеп булмый ул"диган фикерне еш ишетергә туры килә. Кайчандыр авылда белем алып, бүген профессор дәрәҗәсенә күтәрелүегез моның киресен раслый түгелме?**

— Мин авыл мәктәбендә укуыма һичкайчан үкенмәдем. Бу яктан әти-әнием белән дә, укытучыларым белән дә бәхетлемен. Мәктәпнең сыйфатын бит аның тышкы һәм эчке бизәге түгел, ә намуслы укытучылары билгели. Уфада, әлбәттә, баланы укырга биргәндә сайлау мөмкинлеге бар, ә авылда мәктәп — берәү, сайлап утыра алмыйсың. Ә безне иң-иң яхшы укытучылар укытты: математикадан — Асия апа Ханмурзина, физикадан — Нил Еникеев, химиядән — Венера Гыйззәтова, шулай ук Зөһрә Әюпова, Мөнәвәрә апа Латыйпова һ.б. — барсы да үз эшенә мөкиббән киткән, балалар ныклы белем алсын өчен бар җанын биреп эшләгән кешеләр. Мәктәптә гөрләп үткән физика, химия, татар теле, математика кичәләренә барыбыз да ашкынып йөрдек. Укытучыбыз Сәгыйть абый Латыйпов хәтта безне үз йортына алып барып, фотолар эшләү серләрен ачты.

Тагын да төрле предметлар буенча район олимпиадаларына йөргәннәр хәтердә саклана. Мәктәпне тәмамлаганнан соң Уфага килеп, берүзем БДУга документлар тапшырдым. Укырга мин "университетны тәмамлыйм да, авылыма укытырга кайтам" дигән хыяллар белән кердем. Студент еллары — иң күңелле, бәхетле яшьлек еллары. Чын дуслар, саф хисләр, киләчәккә корган пландар — барсы да күңел түрендә саклана. Өченче курста укыганда җитди итеп фәнни эш белән шөгыльләнә башладым. Шулай итеп, авылга укытучы булып кайтырга туры килмәде, университетта кафедрада эшкә калдым. Соңрак Казан дәүләт университетында аспирантура тәмамладым, физика-математика фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклап, БДУда җаңыма якын булган "Геофизика" кафедрасында укыта башладым. Соңрак техник фәннәр докторы дәрәҗәсенә диссертация якладым, профессор дәрәҗәсе алдым.

**– Ни өчен геофизика өлкәсен сайладыгыз?**

— Геофизик кешенең саулыгын тикшереп, диагноз куючы табибка охшаган. Ләкин геофизикның тикшерү объекты — нефть яки газ скважиналары.

Геофизик мәгълүмат алу һәм аны эшкәртү белән шөгыльләнә. Ул физика, математика һ.б. заманча мәгълүмат технологияләрен яхшы белергә, һәрвакыт белемен камилләштереп торырга тиеш. Безнең университетта укытучыларга да, студентларга да заманча ныклы белем алу, шулай ук фәнни эш белән шөгыльләнү өчен барлык шартлар булдырылган.

**– Югары уку йорты преподавателе мәктәп укытучысыннан ни белән аерыла?**

— Тәү чиратта шунысы белән: безгә укытуны фәнни эш (аеруча чыгарылыш кафедраларында) белән бәйләп алып бару мөһим. Әгәр дә кафедрада фәнни тикшеренүләр алып барылмаса, предприятиеләр белән килешүләр буенча грантлар һәм эзләнү-тикшеренүләр үтәлмәсә, яхшы белгеч әзерләү мөмкин түгел. Бу безнең, геофизика кафедрасының, төп девизы!

Мин үз эшемне, студентларымны бик яратам.

**– Фәнни хезмәткәр, фәннәр докторы, профессор дәрәҗәсенә күтәрелгәнче бик озайлы, катлаулы юл үтәргә кирәк. Барсына да кул селтәп, акчаны көрәп ала торган эшкә китәргә кирәк, дигән уй килгәне булмадымы?**

—Әйе, андый чаклар да булды. Ләкин һөнәремне түгел, ә эшләгән урынымны алыштырырга дигәне. Туксанынчы елларда, фән өлкәсе таралып барган, бәйләнешләр өзелгән чорда. Шунысы истә, мине Мәскәү белән Санкт-Петербург арасында урнашкан, еш булырга туры килгән Тверь шәһәренә эшкә чакырдылар. Ләкин моның өчен Уфадагы фатирны алыштырырга кирәк иде. Менә бер көнне Уфага кайтып төпләнергә теләүче хәрби летчик килде, аның белән бүлмәләрне карап йөрибез. Шулчак күрәм: бездә кунакта булган әнием белән олы кызым кочаклашып әкрен генә елап утыралар: озакламый аерылышабыз дип... Моннан соң инде көченеп китәргә дигән уйдан кире кайттым. Соңрак Сургутның нефть фәнни-тикшеренүләр-җитештерү институтына (СургутНИПИнефти) чакырдылар. Уйладым-уйладым да, аннан да баш тарттым. Сәбәбе нинди дисезме? Кафедрабызда искиткеч тату-бердәм коллектив тупланган иде. Шулай ук университетта минем өчен бик тә уңайлы эш шартлары тудырдылар.

**– Айрат Шәйхулла улы, бүгенге абитуриентларның, студентларның белем дәрәҗәсен ничек бәяләр идегез?**

— Бу сорауны миңа бик еш бирәләр. Мин, әлбәттә, кече курсларда укытмыйм, шулай да гомум белем дәрәҗәсе түбәндәр дип әйтә алмыйм. Бүгенге абитуриент моннан 50 ел элеккесеннән күбрәк белә. Монда аңа интернет та ярдәмгә килә, әлбәттә. Мин, мәсәлән, укырга керергә килгәндә русча сөйләшә дә белми идем, ә авылымда үткән очрашуларда укучыларның татар теленнән җиңел генә русчага күчүен күрәм.

Әлбәттә, студентлар арасында төрлесе бар: тырышканнары күп, укуга исе китеп бармаганы да очрый. Ләкин беренчеләре ота һәм зур уңышларга ирешә.

**– Айрат абый, "Өмет" укучыларын якыннарыгыз, гаиләгез белән таныштырып үтегез әле.**

— Мин бик бәхетле кеше: намуслы, бер-беребез өчен җан ярып бирергә әзер булган гаиләдә үстем. Әтиебез Шәйхулла Рәхмәтулла улы 1921 елгы, Бөек Ватан сугышында разведчик булып хезмәт иткән. 1947 елда гына тыныч тормышка кайтып, гомере буена туган авылында укытучы, авыл советы рәисе, аннан колхозның профком рәисе булып эшләде. Безгә, гаиләдә үскән дүрт балага ул намуслылык, тәрбиялелек һәм хаклык яклауның гүзәл үрнәге булды. Авылдашлар өчен авторитет иде. Әтиебез бик матур итеп рәсемнәр төшерә, матур яза иде. Авылыбызның тарихын өйрәнүгә зур хезмәт салды ул. Исемдә: өлкәннәрдән сораштырып, барсын да җентекләп язар иде. "Сәнәк сугышы" дигән мәкаләсе басылганы хәтердә. Стенабызда зур дөнья картасы эленеп торды. Гомеренең соңгы биш елында әти безнең гаиләдә яшәде: әгәр командировкага җыена башласам, картадан хәзер үк шул ноктаны табып ала иде. Укырга яратты, безгә дә туган көнгә матур китаплар бүләк итә иде.Соңгы укыган китабы изге Коръән булды, гарәпчә дә укый-яза белә иде.

Әниебез Мөсаллия Хәким кызы гомере буена башлангыч сыйныфларны укытты. Ул гаять сабыр, тыныч тавышлы, күркәм холыклы булды. Мин аны бүген дә сагынам... Аны балалар да, өлкәннәр дә ярата иде, хәтта авылдагы хатын-кызлар арасында "Мөсаллия апа укытсын иде" дип планлаштырып бала тапканнар дигәнне дә ишеткән булды (моңсу елмая).

Гаиләм — минем терәгем. Белорет кызы Неля белән университетта бергә укыдык һәм кулларыбызга диплом алгач өйләнештек. Ике кызыбыз — Айгөл һәм Лия тулай торакта, студентлар һәм башка гаиләле преподавательләр белән бик матур-күңелле яшәгән елларда туды. Айгөл бүген — икътисад белгече, Лия адвокат һөнәрен сайлады. Мин һәр көнне эшемә сөенеп барам, гаиләмә ашкынып кайтам. "Өмет" укучыларына да шушы бәхетне телим.

**КЕРМИ КАЛГАН ФИКЕРЛӘР:**

*Әлегә кадәр фәнни әдәбият укуны өстен күргән, хәзер "Өмет"кә язылачак.*

*Телевизор карамаска тырыша, чөнки һәр алынган мәгълүмат турында фикерләргә, чагыштырырга, җавапларны үзе табарга тели.*

*Шунда ук барсына да ышанып бармый.*

*Кешедә изгелек, гадилек, намуслылык, җаваплылык сыйфатларын хөрмәт итә.*

*Ачу сакламый, кемдер үзенә зыян эшләсә, яңа мәсьәләләр белән мавыгып, оныта.*

*Яшьлегенә кайтса, бернәрсәне дә үзгәртмәс иде. Хәер, "мәктәптәге артык шаян, тыңлашмаган малайлар белән җитди сөйләшер, башкаларга белем алырга комачауларга юл куймас идем. Һәм әти-әниләрен озаграк яшәтү өчен бар тырышлыгымны салыр идем",— ди геробебыз.*

Гөлара АРСЛАНОВА.

**“ГЕРОЙ-АНА” ИСЕМЕ 2022 ЕЛНЫҢ 15НЧЕ АВГУСТЫННАН ЯНӘ БИРЕЛӘ БАШЛАДЫ. АНЫ КАЙТАРУ ТУРЫНДАГЫ УКАЗГА НӘКЪ ШУЛ КӨННЕ РУСИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ ВЛАДИМИР ПУТИН КУЛ КУЙДЫ. БАШКОРТСТАНДА МӘРТӘБӘЛЕ ИСЕМГӘ БЕРЕНЧЕ БУЛЫП ИСКЕ БАЛТАЧ АВЫЛЫНДА ЯШӘҮЧЕ АЛЬБИНА ХӘЙДӘРШИНА ЛАЕК БУЛУЫН РАЙОНДАШЛАРЫ ГЫНА ТҮГЕЛ, Ә РЕСПУБЛИКА ХАЛКЫ ДА ИХЛАС ШАТЛАНЫП КАБУЛ ИТТЕ.**



# “Батыр ана”

## Бу дәрәҗәле исемгә Башкортстаннан беренче булып Балтачта яшәүче Альбина Хәйдәршина лаек булды

Русия Президенты Владимир Путин, Альбина Рәиф кызын тантаналы рәвештә дәрәҗәле исем бирү уңаеннан тәбрикләп, “Герой ана“ орденын тапшырды. Башкаладагы тантаналы чарада ихлас теләкләр, чәчәк гөлләмәләре, хәтердә калырлык тәэссоратлар...

Тату гаиләдә алар Винер Флүр улы белән 13 бала тәрбияләп үстерәләр. Олы кызлары Элитага 29 яшь, кечеләре Байрас — нарасый. Элита Исхакова гаиләсе белән Бөре шәһәрендә яши, тормыш иптәше белән ике бала тәрбиялиләр. Уллары Артур аграр университетны тәмамлап, әтисе белән Уфа шәһәрендә төзелеш оешмасында көч сала. Альмир Уфа дәүләт нефть техник университетын тәмамлап, армиядә хезмәт итеп кайтты. Лаеклы хезмәте командованиенең Почёт грамотасы белән билгеләнде. Ә Айгизне Балтач тамашачысы яхшы белә. Моңлы җырлары белән бала чагыннан ук сәхнәдән төшкәне юк. Әлеге вакытта Уфа сәнгать училищесында укып йөри, конкурсларда актив катнаша, лауреат исемнәренә лаек була. Айназ автотранспорт техникумында укый. Һәркайсы спортта да яхшы нәтиҗәгә ирешә.

Мәктәптә укыган Айзилә кызлары матур итеп рәсем ясый, Нурсилә җырлый, Инзилә бию белән шөгыльләнә. Башлангыч сыйныфларда укучы Айгүзәл район гимнастлары составында инде күп тапкырлар җиңүгә ирешә, ә Айнур шулай ук халык биюләрен ярата. Назгөл һәм Ислам балалар бакчасына йөри. Хәйдәршиннар һәр бала тормышта үз урынын табар дип хыялланалар.

Альбина Хәйдәршинаны “Герой ана” исеменә лаек булуы белән район җитәкчелеге исеменнән хакимият башлыгының кадрлар һәм социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Инзилә Гасыймҗанова тәбрикләде.

“Без бу югары исемгә лаек булуыгыз өчен бик шатландык. Сез — матур гаилә. Без сезне хөрмәт итәбез. Без сездән үрнәк алабыз. Дөньягыз матур, балалар тырышлар. Алар спортта да, укуда да алдынгылар. Без сезнең өчен бик шат”,—дип чәчәк гөлләмәсе һәм кыйммәтле бүләк тапшырды.

Альбина Рәиф кызы хатирәләре белән уртаклашты: “Бу юлы ике кеше “Герой ана” исеменә лаек булды. Русия Президенты Владимир Путин шулай ук үз эшенең осталарына дәүләт наградалары тапшырды. Тантанага килгән хатын-кызлар белән аралашты, фикерләрен тыңлады, сораулар бирде. Мәскәүдәге тантана хәтердә калырлык булды.

Аэропортта Альбина Рәиф кызын тормыш иптәше һәм өлкән балалары каршы алды. Нинди зур сөенечле булды бу ел Хәйдәршиннар өчен. Кечкенәләре Байрас әнисе бүләк алган көннәрдә тәпи киткән.

**Рима ВӘЛИЕВА-КАҺАРМАНОВА.**
Балтач районы.
**Газим ТАЛИПОВ фотосы.**





# Ирекмәннәр иренмәгән халык

Штабны яшьләр үзәге директоры Альбина Янбухтина җитәкли. Аның эшендә 50 дән артык волонтер катнаша.

Битараф булмаган кешеләр мобилизацияләнүчеләрнең якыннары нинди кыенлыклар кичерә, шул хакта хәбәр итәләр. Волонтерлар балалары булган гаиләләргә кирәкле товарларны китерәләр. Гуманитар һәм юридик ярдәм күрсәтү мөмкинлеге дә карала. Шулай ук сугышчыларыбызга гуманитар ярдәм җыялар.

Бүгенге көндә штабка халыктан алтмыштан артык мөрәҗәгать кергән. Гаризалар шулай ук республика колл-үзәгенә, район хакимиятенә, «Бердәм Русия» партиясенең урындагы бүлекчәсенә, авыл хакимиятләренә җибәрелә. Ярдәм итү эшендә волонтерлар, район хакимияте, авыл советлары, ветераннар оешмалары вәкилләре, эшкуарлар, барлык дәрәҗәдәге депутатлар, битараф булмаган халык катнаша.

— Бүздәк районында хәйриячеләр исемлеге аз түгел. Күпләр үзләренең яхшы эшләрен язмаска тырыша. Җирле эшкуарлар, районның битараф булмаган кешеләре ярдәме белән азык-төлек җыелмалары буенча заявкалар эшләнә. Заявкаларның күпчелеген утын сатып алу һәм китерү, шулай ук йорт хайваннары өчен печән һәм салам китерү мөрәҗәгатьләре тәшкил итә, — диде Альбина Азат кызы.

2022 елда 8 ирекмән Луганск Халык Республикасындагы М. Шәйморатов исемен йөрткән 22нче Петровка мәктәбен тергезүдә булышлык күрсәткән. Шулай ук, Бүздәк районы юл-ремонт төзелеш идарәсенең 5 хезмәткәре Красный Луч шәһәрендә юл тергезүдә ярдәм иткән.

2023 елның февралендә шәхси эшкуарлар, крестьян-фермер хуҗалыклары башлыклары, битараф булмаган халык һәм Бүздәк районыннан чыккан кешеләр көче белән ирекмәннәр мобилизацияләнгән солдатлар өчен гуманитар ярдәм җыйган. Гуманитар конвой сугышчылардан килгән гаризалардан чыгып формалаштырылган. Район делегациясе махсус хәрби операция зонасына “УАЗ” һәм 4 “Нива” автомобиле, адреслы посылкалар, бензин пычкылары, генераторлар, көрәкләр, азык-төлек, утын һәм башкаларны китергән.


Кызганычка каршы, махсус хәрби операциядә катнашучы Бүздәклеләр арасында югалтулар да бар. Биш егет (Илмир Гыймалетдинов, Максим Ядров, Ленар Еникеев, Руслан Пупков, Фируз Минибаев) хәрби бурычларын үтәгәндә һәлак булган. Аларның гаиләләренә төрле ярдәм күрсәтелеп, ата-аналар һәм якыннары районда патриотик чараларга чакырыла, һәлак булучылар хөрмәтенә мемориаль такталар ачыла.

Бирегә волонтерлык эшчәнлеге барысының да: хакимият башлыгы Ильнур Игдиевнең, депутатларның, авыл советлары башлыкларының, оешмаларның һәм районның битараф булмаган бөтен халыкның бердәм көче белән тормышка ашырыла.

**Ильфира НИГЪМӘТУЛЛИНА.**

podpiska.pochta.ru

**Соңгы вакытта үзләрендә утлы яисә башка төр корал булдырырга теләүче кешеләр саны арта. Корал сатып алырга теләүчеләргә карата таләпләр катгыйланса да, аны явыз нияттә кулланучылар саны кимеми. Безнең илдә "Корал турында"гы Федераль Закон иң еш үзгәреп торучы һәм өстәмәләр кертелүче законнарның берсе. Яңа Русиядә беренче тапкыр ул 1996 елның 13 декабрендә дөнья күрә. Законның җитешсезлекләре күренеп һәм аңлашылып торса да, озак еллар дәвамында ул үзгәрешсез кала килде.**




# Корал түгел, кеше үтерә!

Көнбатыш фильмнарындагы атыш-үтерешләрне карап аңнары томаланган яшьләр саны арта башлагач, Хөкүмәт һәм хокук саклау органнары, хәтта гади гражданнар законны кырыслату кирәклеге турында таләп итә. Чөнки төрле төбәкләрдә, аеруча уку йортларында ату-үтерешләр башланды. Бу илебездәге иң зур һәм куркыныч проблемаларның берсенә әйләнде. Яшьләрдә, хәтта үсмерләрдә пневматик корал алып атышу, янау кебек күренешләр тискәре бер модага әверелә башлады. Чөнки бу төр коралны сатып алуга бернинди җитди таләпләр һәм яшь чикләүләре дә юк иде. Безнең республика парламенты, илдә беренчеләрдән булып, законга үзгәрешләр кертүне күтәреп чыкты. Дәүләт җыелышы — Корылтайның закон проектлары Дәүләт Думасына әзерләп тапшырылды. Анда сүз 18 яше тулмаган гражданнарга пневматик корал сатуны тыю хакында бара иде. Мондый корал эчкече һәм наркоманнар, психик авыру кешеләр кулына да эләгергә тиеш түгел. Аны ирекле сату гражданнар гомеренә һәм сәламәтлегенә хәвеф белән яный. Ул эш өчен кирәк кешеләргә генә сатылырга тиеш. Мәсәлән, сунарчыларга, спортчыларга, спорт-техник оешмаларга, ату тирларына", — дип үз карашын белдергән иде **республика парламенты спикеры Константин Толкачев.**



Әлеге закон 2019 елның 15 гыйнварыннан тулысы белән үз көченә керде. Ул вакытта канун корал сату, аны саклау һәм куллану буенча бик зур таләплəр куйды. Бу закон проектын әзерләгән вакытта илдә корал сатуны бөтенләй тыярга кирәк дигән тәкъдимнәр дә бик күп яңгырады. Әмма алар, корал кулланунының төп сәбәбен онытып җибәрәләр булса кирәк. Корал тик торганнан беркайчан да үзеннән-үзе атмый. Аның дуамал, психик яктан тотрыксыз кешеләр кулына эләгүе иң зур бәла булып тора. Ату коралы андый вәхшиләр кулына эләкмәсен өчен, тәү чиратта, ныклы медицина тикшерүе үткәрергә кирәк. Югыйсә медицина тикшерүе түләүлегә әйләнеп беткәч, күп җирдә ул формаль рәвештә генә үткәрелә башлады.



**Дәүләт Думасының экология һәм тирә-як мохитне саклау комитеты рәисе урынбасары Николай Валуев** бернichә ел буена бу мәсьәләне күтәреп килде.

— Корал сатып алуга лицензия бирүне күпкә каттыйлатырга кирәк иде. Яңа законда да бу өлкәгә тиешле игътибар бирелмәде. Димәк, кайбер депутатлар да бу мәсьәләнең җитдилеген аңлап бетермиләр. "Аучы таныклыгы" бирүгә күп җирдә бик җиңел карыйлар. Мәсәлән, водитель таныклыгы алыр өчен кешенә 2-3 ай укырга һәм күп төр имтихан тапшырырга кирәк. Ә аучы таныклыгын алганда ник шулай эшләнми? Нәтиҗәдә, лицензиясе була торып та корал белән ничек эш итәргә белмәгән кешеләр саны арта. Соңгы елларда, аеруча яшьләр арасында, психик яктан тотрыксыз кешеләр арта. Иртәме-соңмы, медицина тикшерүен, катгыйлатырга кирәклеге проблемасына әйләнеп катгыйлатырга туры киләчәк. Бу законда ук бу мәсьәләне җентекләп тикшереп, таләпләрне кырыслатырга кирәк иде, — диде депутат.

Депутат сүзләренең дөреслеген тормыш һәм ачы хакыйкать үзе раслады. 2021 елның май аенда Казан шәһәрендәге атыштан соң, Русия Президенты Владимир Путин теләсә нинди коралга ия булу кагыйдәләрен катгыйлатырга боерды. 2022 елның 1 мартыннан корал сатып алырга теләүчеләр медицина тикшерүен бары тик дәүләт медицина учреждениеләрендә генә үтәргә тиеш дигән карар гамәлгә керде. 2022 елның июнь аенда Владимир Путин коралны 21 яше тулган һәм медицина чикләүләре булмаган кешеләргә генә сатарга ярый дигән законга кул куйды. Аңа кадәр лицензия 18 яшьтән бирелә иде. Яңа таләпләр белән медицина тикшерүен 5 ел саен үтеп торырга кирәк булачак. Кешенең психик хәле яисә күз күрүчәнлеге начарайса, корал тартып алыначак.

Әйткәнемчә, узган елның 1 мартыннан водитель таныклыгы һәм коралга лицензия алу өчен медицина тикшерүен дәүләт медицина учреждениеләрендә генә үтәргә була. Бу Сәламәтлек саклау министрлыгының бердәм мәгълүмат системасын булдыру өчен кирәк иде. Бер ел эчендә әлеге мәгълүмат системасы тупланган һәм быел 1 марттан ЮХХДИ инспекторлары теләсә кайсы водительнең сәламәтлеге торышын әлеге система аша белеп торачак. Сәламәтлек буенча чикләүләр булса, водитель таныклыгы гамәлдән чыгарылачак. Корал алырга теләүчеләрне дә шушы язмыш көтә. Росгвардия яисә Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәре шушы ук мәгълүмат системасына кереп, нинди дә булса коралга ия булган кешенең сәламәтлеген тикшерә алачак. Чикләүләр яисә сәламәтлек буенча тайпылышлар булса, аучы таныклыгы, лицензия һәм корал тартып алыначак.

Статистикага күз салсак, бүгенге көндә Русиядә 5 миллионлап кешедә 7 миллион 120 мең корал теркәлгән. Теркәлмәгәне 3 миллионлап дигән фаразлар бар. Аның янына 1 миллион 470 мең пневматик коралны да өстәргә кирәк. Кайбер Европа илләренең армиясендә дә бу кадәр корал юк. Нигә кораллана соң халык? Кайбер белгечләр моны күп елларга сузылган кризис, халыкның түләү сәләте киму, милеккә кул салырга теләүчеләрнең саны арту һәм даими стресс дәрәҗәсендә яшәү рәвеше белән бәйләп аңлаталар. Кулдагы 7 миллионнан артык коралның ел саен 600 дән артыгы явыз нияттә кулланыла. Корал куллану юлларда водительләр арасында килеп туган низагларда, йорттагы ызгышулар вакытында, исерек төркемнәр сугышканда, кешене талау нияте белән янаган очраклар арткан.

Яшьләр чын хәрби пистолетка охшатып эшләгән травматик коралга өстенлек бирә. Аның хәзер нинди генә юк? Аларны хәрби кораллдан бары бу өлкәдә хезмәт салучылар гына аера ала. Җәрәхәт салу өчен генә дип җитештерсәләр дә, аларның үлем очрагына китерүен дәлилләгән мисаллар дистәләрчә. Аннары, аларның төзелешенә бернидәр үзгәрешләр керткәннән соң, хәрби пулялар белән атуга көйләнгән очраклар ешайды. Алай гына да түгел, моны табышлы кәсепкә әйләндергән җинаятьче төркемнәр барлыкка килде.

Мисал өчен, 2022 елның ноябрь-декабрь айларында Федераль иминлек хезмәте Русиянең 38 төбәгендә законсыз корал ясаучы җинаятьчел төркемнәрне ачыклау буенча массакүләм рейдлар үткәргән. 2023 елның 31 гыйнварында аның нәтиҗәләре игълан итөлде. Бу рейдлар вакытында 93 кешедән торган легаль булмаган корал җитештерүче һәм сатучы 40 җинаятьчел төркемнең эшчәнлегенә чик куелган. Аларга карата җинаять эше кузгатылган. Бәйрәм алдыннан, ягъни 7 март көнне, тагын 34 төбәктә 59 җинаятьчел төркемнең кулга алынуы хакында хәбәр ителде. Алардан 10 пулемет, 26 автомат, 17 пистолет-пулемет, 106 пистолет һәм револьвер, 11 гранатомет, 89 граната, 316 детонатор, 160 кг тротил, 40600 патрон тартып алынган. Мондый вәзгыятьтә корал әйләнешен контрольдә тоту өчен тагын да кырысрак законнар кирәклеге көн кебек ачык.

2023 елның 29 мартыннан "Корал турында"гы законның өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертелгән варианты үз көченә керәчәк. Яңартылган закон буенча беренче тапкыр корал алырга теләгән гражданнарны алдан ук җитди тикшерү көтә. Аның буенча кешенең сәламәтлеге генә түгел, "гражданнарның хокуклары һәм ирекләрен бозу куркынычы, дәүләт яисә җәмгать хәвефсезлегенә янау мөмкинлеге" тикшерeләчәк. Тикшерү эчке эшләр органнары һәм Федераль иминлек хезмәте тарафыннан "оператив-эзләү бүлекләре" катнашлыгында үткәреләчәк. Кеше нинди дә булса хокук бозуда шикләнелсә, лицензия бирелмәячәк һәм корал сатылмаячак.

## Лицензия тагын кемнәргә бирелмәячәк?

Беренче чиратта, белә торып җинаять эшендә шикләнүчеләр һәм гаепләнүчеләр. Икенче чиратта, суд карары нигезендә хокук төзәтү урыннарыннан чыгарылган, әмма реабилитация үтмәгәннәр. Мәсәлән, ике яклы килешү буенча гаепләне төрмәгә утыртмаган очраклар да еш кына булып тора. Мисал өчен, үлем очрагына китергән авария ясаучылар. Килешү буенча каза күрүченең туганнары гаепләне кичерсәләр дә, бу очрак корал һәм лицензия алуга киртә булып торачак.

Законга тагын бер җитди өстәмә кертелде. Водитель спиртлы эчемлекләр яки наркотик матдәләр куллануда шикләнелеп тә медицина тикшерүе үтүдән баш тартса, коралга лицензия алуга чикләүләр кертелә. Әчеп тотылган яисә медицина тикшерүеннән баш тартканнарның водитель таныклыгын 1,5-2 елга тартып алалар. Шушы вакыт үткәннән соң тагын 1 ел дәвамында коралга лицензия алып булмаячак. Әгәр Эчке эшләр органнары яки Федераль иминлек хезмәте кешегә "җәмгыять өчен куркыныч" дигән бәяләмә бирсә, бу кешегә коралга лицензия бөтенләй бирелмәячәк. Бүгенге көндә кулында коралга лицензиясе булган гражданинны да шундый ук тикшерү аша үткәрү хокукы бирелә Җәмгыятькә хәвеф тудырырга мөмкин дигән кечкенә шик булса да аның коралы һәм лицензиясе тартып алыначак.

Участок инспекторы үзе күзәтчелек иткән җирлектә эчкече һәм гаугалы кешеләрне белеп тора. Андыйлар кулында да рәсми теркәлгән һәм лицензияле корал бихисап. Әлегә кадәр андыйлар корал саклау тәртибен үтәмәсә, яисә җәмәгать урынында корал күтәреп йөрсә, аларга штраф салалар, яисә 15 көнгә ябып куялар иде. Яңа закон нигезендә участок инспекторы белешмәсе буенча андый гаугалы һәм эчкече кешеләргә дә лицензия бирү һәм корал сату тыелачак.

Узган атнада гына да Новосибирск һәм Иркутск өлкәләрендә ике ир кешенең явыз нияттә корал куллануын зәңгәр экраннар аша күрдек. Берсе урамда атыш оештыра, икенчесе фатир балконыннан ут ача. Әлегә кадәр җәрәхәтләнүчеләр булмаса, аларга административ штраф кына салына иде. Коралын тартып алырга рөхсәт ителмәде. Яңа законга ярашлы, корал бернинди суд карарын да көтмичә, тартып алыначак. Күптән шундый кырыс закон кирәклеген гади кешеләр дә, хокук саклау органнары да, депутатлар да белеп торалар иде. Чөнки корал үтерми — кеше үтерә. Тик нигәдер, андый законнар кабул иткәнче, дистә еллар үтеп китә. Ни өчен шулай?

**Рәдиф ФӘТХИ.**



# Кызларыбыз җиңү яулый

**Русия Фехтование федерациясенә төрле яклап басым ясалса да, спортчыларыбыз бирешми. Уфа спортчысы Аделина Зәһидуллина Иран дәүләтендә узган халыкара ярышларда бронза медаль яулады.**

Башкортстанның Олимпия чемпионы, чирекфиналда Арина Камалетдиновалы 15:5 исәбе белән җиңеп, өченче баскычка күтәрелде. Аңа кадәр Аделина Мәскәү өлкәсенең Новогорск шәһәрендә үткән Бөтенрусия чемпионатында да бронза медаль яулаган иде. Русиянең фехтование буенча җыелма командасы дөньяда иң көчлеләр исемлегенә керә. Шуңа да көндәшлектән куркып, безнең спортчыларны дөньякүләм ярышлардан читләштерергә теләүчеләр күп. Бу бик күңелсез яңалык, чөнки дөнья чемпионатында катнашмасак, Русия җыелмасын киләсе Олимпия уеннарына кертмәячәкләр.

# Яшь хоккейчыларыбыз өченче!



**Башкортстанның хоккей буенча яшьләр командасы беренче тапкыр Русия чемпионатының бронза медален яулады.**

Ил беренчелеге Түбән Новгород өлкәсендә үткәрелде. Анда Русиянең 18 яшькәчә спортчыларыннан торган иң көчле командалары катнашты. Ярымфинал һәм финал уеннарына барып җитү дә безнең өчен зур уңыш итеп кабул ителер иде. Чөнки дүрт этаптан торган бәйгенең ахырына илнең иң яхшы Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре, Свердловск, Түбән Новгород, Воронеж өлкәләре җыелма командалары гына торып калды. Яшьләребез, үз осталыкларын күрсәтеп, бронза баскычка күтәрелә алдылар.

Әйткәндәй, бүгенге көннәрдә Русия хатын-кызлар хоккей лигасының плей-офф уеннары бара. Өч тапкыр Русия чемпионы, безнең "Агыйдел" хоккей командасы регуляр чемпионатны беренче баскычта тәмамлады. Кызларыбыз 32 уенда 81 очко җыя алды. Плей-оффның беренче этабында җиңеп, чирекфиналда кызларыбыз Түбән Новгородның "Торпедо" командасы белән көч сынашачак. Уңышлар теләп калабыз.


# "Калтасы"ның алтын баскычы



**Бозда мотоциклда узышу буенча Русия Кубогы ярышларында алтын һәм бронза алуга ирештек. Башкортстанның Калтасы районыннан "Калтасы" спорт-техник клубы командасы, Русия Кубогы ярышлары финалында җиңеп, алтын баскычка күтәрелде.**

Әлегә кадәр Русия Кубогын авыл командасының яулаганы булмаган. Бу инде икеләтә уңыш һәм Русия мотоспорты тарихына кереп калу дигән сүз. Илнең иң көчле командалары белән ярышып Күмертау шәһәренең "Вымпел" командасы бронза медаль алуга иреште. "Вымпел" командасы өчен чыгыш ясаган Евгений Шаровны чын герой дип атарга була. Мизгел алды узышларында ул кулын сындырган булган. Шуңа карамастан, тиз арада күнегүләр башлый һәм Русия Спорт министрлыгы медаленә лаек була. Күмертау командасы легендар узышчыбыз, алты тапкыр дөнья чемпионы Габдрахман Кадыйров исемен йөрткән техник спорт төрләре үзәгенең икенче командасы булып тора. Командага Русиянең атказанган тренеры Рәис Мостафин җитәкчелек итә. "Калтасы" клубының уңышын Калтасы районы хакимияте башлыгы Зәбир Габдуллин белән бәйлиләр. Афәрин, егетләр һәм җитәкчеләр!

# Семен, афәрин!



**Башкортстан башкаласы икенче тапкыр тимераякта шуу буенча Русия чемпионатын кабул итте.**

Русиянең иң көчле спортчылары шәхси узышларда һәм эстафета бәйгеләрендә көч сынаштылар. Дөнья күләмендә иң дәрәҗәле җиңүләр яулаган якташыбыз Семен Елистратов бу юлы да сынатмады. Семен 1500 метр араны 2 минут 11 секунд эчендә шуып узып алтын медаль яулады. Финиш сызыгын үтү белән Башкортстан Башлыгы Радий Хәбиров җиңүчене котлады. "Семен Елистратовны һәм аның тренеры Андрей Максимовны чираттагы җиңү белән котлыйм. Русия чемпионаты Семен Елистратов исемен йөрткән шорт-трек үзәгендә үткәрелә. Бу да күп нәрсә турында сөйли", — диде Радий Фәрит улы үзенең телеграм-каналында.

# "Салават Юлаев" көрәштән төшеп калды

**Белүегезчә, яраткан командабыз, плей-офф уеннарында Владивостокның "Адмирал" командасына 4:2 исәбе белән оттырып, быелгы мизгел уеннарын төгәлләде.**

Башкортстан хоккей сөючеләренең берсе дә болай булыр дип көтмәгәндер. Чөнки командабыз регуляр чемпионат матчларында яхшы уен күрсәтеп, Көнчыгыш Конференциядә икенче баскчына күтәрелде. Плей-офф уеннарында регуляр чемпионатны җиденче баскычта тәмамлаган "Адмирал" командасына каршы көрәшергә туры килде. Бездән күпкә түбән булган команданы тиз генә җиңәрбез кебек иде... Әллә каршы як команданы җитди кабул итмәү бәласе булдымы бу? Ни генә булса да яраткан уенчыларыбызны күрер өчен киләсе уен мизгелен көтәргә кала инде. Җиңелү сәбәпләрен төрлечә аңлаталар. Сезгә аларның берничәсен тәкъдим итәбез.



**"Салават Юлаев" командасының баш тренеры Виктор Козлов** аңлатмасы:

— Бик кызганыч, "Адмирал" командасы белән үткәргән уеннарда көчләр тигез дәрәҗәсендә булды. Әмма без үз капкабызга бернинди логика белән аңлата алмаслык голлар керттердек. Көндәшләр һәрбер уен очрагын файдалана белделәр. Аннары безнең командада яшь спортчылар да күп иде бит. Яшьләр үзләрен күрсәтергә тырыштылар, бирелеп уйнадылар, әмма тәҗрибә җитмәгәнлеге сизелеп тора иде. "Адмирал" капкачысы Серебряков үзен команданың иң көчле спортчысы итеп танытты. Регуляр чемпионатта да ул иң аз гол керттергән капкачы булып билгеләнде бит. Плей-офф матчларында да ул искиткеч уен күрсәтте.

**"Салават Юлаев" командасының элеккеге капитаны Игорь Григоренко:**



"Хәзер барсы да баш тренер Виктор Козловны гаепләргә керешәчәкләр. Уен мизгеленең шулай тәмамлану ихтималы көзге айларда ук аңлашыла иде бит инде. Тәҗрибәле уенчылар китте, алар урынына яшьләр алынды. Яшь спортчылар үзләренә күрсәтелгән ышанычны акларга тиеш иде. Чөнки күреп тордылар, бу мизгелдә барлык җаваплылык алар иңендә. Алар үз дәрәҗәсендә уйнадылар, әлбәттә. Әмма кайбер уенга төшенке кәеф һәм ихтыярсыз чыгулары сизелә иде. Соңгы уен бик җаваплы икәнлеген аңлап тордылар бит, көрәшергә кирәк андый чакта. Хо-Сэнг кебек лигионер уенчыны командага алуны да аңлап бетмәдем мин. Ни булса да баш тренерны гаепләячәкләр инде".



Командабызны **Александр Хмелевский** күтәрмәсә, регуляр чемпионатны ничек тәмамлар идек икән? Александр регуляр чемпионатта 48 очко (26 шайба һәм 22 пас) җыеп, иң яхшы һөҗүмче исеменә лаек булды. Плей-офф уеннарында да 5 очко җыйды. Иң куанычлысы шул, "миңа Уфа, команда һәм җанатарлар бик ошый, баш тренер Виктор Козлов белән уйнар өчен "Салават Юлаев" белән контрактны озайтам" — диде Александр.

"Салават Юлаев" клубы җитәкчелеге элеккеге уенчыбыз, 2016, 2017 елларда Анатолй Емелин һәм Игорь Захаркинның ярдәмчесе булган Андрей Зюзинны команданың спорт буенча директоры вазифасына алу мәсьәләсен карый башлаган.

Плей-офф дәвам итә. Безне ялга озаткан "Адмирал" командасы арытаба "Ак Брас" командасы белән көч сынашачак. Казан командасы ни күрсәтер, алда күрербез.

Аллаһ ярдәм бирсен күршеләргә, диясе генә кала инде.

**Рәдиф ФӘТХИ.**

podpiska.pochta.ru

Динебез – Ислам

# Рамазан – догалар ае

**“ДОГА КЫЛУ – ИҢ ГҮЗӘЛ ГЫЙБАДӘТ”, - ДИДЕ АЛЛАҺНЫҢ БӨЕК ИЛЧЕСЕ МӨХӘММӘД САЛЛӘЛЛААҺУ ГӘЛӘЙҺИ ҮӘ СӘЛЛӘМ. ИЗГЕ РАМАЗАН АЕ КҮП ДОГАЛАР КЫЛУ, АЛЛАҺКА ЯКЫНАЮ ӨЧЕН ИҢ БӘРӘКӘТЛЕ ВАКЫТ. ШУЛ МӨМКИНЛЕКНЕ НӘТИҖӘЛЕ ФАЙДАЛАНУ ӨЧЕН ГӘЗИТ УКУЧЫЛАР СОРАВЫ БУЕНЧА АЛЛАҺУ ТӘГАЛӘНЕҢ 99 ИСЕМЕН КУЛЛАНЫП ДОГАЛАР КЫЛУ ҮРНӘГЕН БЕРНИЧӘ САНДА БИРӘБЕЗ. УЛ АЛЛАҺНЫҢ ИСЕМ ҺӘМ СЫЙФАТЛАРЫН ӨЙРӘНҮ ӨЧЕН ДӘРЕС ТӘ, ДОГАЛАРНЫҢ КАБУЛ БУЛУЫНА ИРЕШҮ ӨЧЕН МӨМКИНЛЕК ТӘ БУЛЫР, ИН ШӘӘ АЛЛААҺ! РАМАЗАН АЕ МӨБӘРАК БУЛСЫН! ДОГАЛАРЫБЫЗ КАБУЛ БУЛСЫН, ИЗГЕ МАКСАТЛАРЫБЫЗГА ИРЕШҮ ӨЧЕН ИШЕКЛӘР АЧЫЛСЫН!**



## Аллаһу Сүбхәәнә вә Тәгаләнең күркәм булган 99 исеме белән дога

**Бисмилләәһир-Рахмәәнир-Рахиим.**

**Әлхәмдүлилләәһи Раббильгәәләмииин.**

**Әшһәдүән ләәәә иләәһә илләллааһу үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән гәбдүһү үә расүүлүһ. Салләллааһу гәләйһи үә сәлләм.**

**Әлхәмдүлилләәһи Раббильгәәләмииин. Аллаһүммә салли гәләә сәййидинәә Мүхәммәдин үә гәләә әәлиһи үә сахбиһи үә бәәрик үә сәллим.**

***Әллааһү әкбәр! Әллааһү әкбәр, ләәәә иләәһә илләллааһү үәллааһү әкбәр! Әллааһү әкбәр үәлилләәһил хәмде!***

*Аллаһ Бөек!Аллаһ Бөек! Аллаһудан башка иләһ юк!Аллаһ Бөек!Аллаһ Бөек!Аллаһуга — мактау.*

***СүбхәәнӘллааһи үәл- хәмдүлилләәһи үә ләә иләәһә илләллааһү үәллааһү әкбәр, үә ләә хәүлә үә ләә куәтә илләә Билләәһил- Галиййиль Газыйм.***

*Аллаһуга дан! Аллаһуга мактау! Югары һәм Бөек Аллаһудан башка иләһ юк. Аллаһ Бөек! Аллаһудан башка беркемдә дә көч һәм куәт юк.*

***Ләәәә иләәһә илләл-лааһү үәхдәһү ләә шәриикә ләһү, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмдү йүхйии үә йүмиит, бийәдиһил хайру үә һүвә гәләә күлли шәйин Кадиир.***

*Аллаһудан башка иләһ юк. Ул Бердәнбер, Аңа тиңнәр юк. Ул барлык тере затлар өстеннән хакимлек итүче. Аңа — Мактау. Ул безгә гомер бирә һәм Ул безне аннан мәхрүм итә. Бары тик Ул гына барлык нигъмәтләрнең Хуҗасы. Ул бар нәрсәгә Кодрәтле!*

**БИСМИЛЛӘӘҺИР-РАХМӘӘНИР-РАХИИМ.**

**Куль һүвӘллааһү Әхәде. Әллааһү-с-Самәде. Ләм йәлиде үә ләм йүүләде үә ләм йәкүлләһүү күфүвән Әхәде.**

**ЙӘӘ, РАББЫМ!** Мин - Синең бер колың: Син - Аллаһ!- дип шәһадәт китердем. Син — Бердәнбер, Син һичкемгә мохтаҗ түгел. Һичкемне тудырмадың һәм тумадың. Һичкем Сиңа тиңдәш булмады.

**ЙӘӘ, РАББЫМ!** Дөнья һәм ахирәт хаҗәтләре белән Синең ярдәмеңне сорап бер Үзеңә мөрәҗәгать итәм. Синең бирүеңдә дә , алуыңда да хикмәтләр бар.

**ЙӘӘ, РАББЫМ!** Мин бары тик Сиңа гына, Синең Рәхмәтеңә өметләр баглыйм һәм бары тик Сиңа гына, кимчелектән пакь булган күркәм исемнәрең һәм тулы сыйфатларың белән мөрәҗәгать итәм.

Догаларымны кабул ит, күтәрелгән кулларымны буш төшермә!

**ЙӘӘ, РАББЫМ!** Син — Мәңгелек, Тере, Син Үлемсез Зат, Син Мәңге бетмисең, Мәңге булучысың. Синең башлангычың да ахырың да юк. Син — галәмдәге бөтен нәрсәне юктан бар итүче, бөтен галәмнәрне яралтучы. Сиңа гына тәвәккәл кылам, бөтен барлыгымны, үземне Сиңа тапшырам. Йәә, Аллаһым! Догаларымны ишет! Синең ризалыгыңны өмет итеп, Синең Мәңгелек җәннәтеңне өмет итеп уразамны тотам. Рәхмәтеңнән мәхрүм итмә, Раббым!

**Йәә, АЛЛААҺ!** Син — безнең Раббыбыз, без — Синең бәндәләрең, колларың. Барыбыз да Синең идарәң астында яшибез. Син — Бар булучы Зат. Синең Бөек исемнәрең бар. Шул исемнәрең белән Сиңа мөрәҗәгать итәм.

Син- **Әль-ӘХӘДҮ** - Син, Раббым Бер генәсең, Синең тиңдәшең юк.

Син- **Әль-ВӘӘХИДҮ** - Син Охшашың булмаган Бердәнбер Зат.

**Әль-ХӘЌЌУ** - Син Хакыйкый, Чынлыкта бар Булучы.

**Әль-ВӘӘҖИДҮ —** Син - һәрвакыт Бар булучы Зат, Синең ихтыяҗың юк.

**Әль-БӘӘТЫНҮ**. Йәә, Раббым! Син - Яшерен, без Синең халәтеңне, рәвешеңне белә алмыйбыз.

**Әҙ-ҘААҺИРУ** - Сине ачык, Бар һәм Бер буларак күрә алмыйбыз, әмма күргән һәр нәрсә Синең барлыгыңны дәлилли.

**Әль-ХӘЙЙҮ —** Син - даими Тере, Үлемсез Зат.

**Ән-НУУРУ**-Син-күкләрнең һәм җирнең Нуры, Нурландыручы. Син безләрне көферлек караңгылыгыннан иман нурына, ширек караңгылыгыннан тәүхид яктылыгына, наданлыктан гыйлем нурына, гөнаһ һәм бозыклык караңгылыгыннан итәгать нурына чыгардың. Безне иманлы иттең. Йәә, Раббым! Чиксез шөкерләр Сиңа! Безгә ныклык та бир, чөнки нык булмаган иман дөньяда һәм ахирәттә коткармый.

Күңелләребездәге һидәять нурын сүндермә, тәүфыйкь бир, калебләребезне нурландыр. Һәрнәрсәдә Синең барлыгыңны танырга, фикерләргә аң-зиһен бир. Безне туры юлыңнан чыгарма, иманыбызны сөекле ит, көферлекне күңелләребезгә кертмә, йөзләребезне нурландыр. Үзеңә ихлас гыйбәдәт кылучылардан ит.

Үзеңнең Бөек китабың, гыйлем диңгезе булган Коръәнне калебләребезнең язы, күкрәкләребезнең нуры итсәң иде. Коръән белән кайгы-хәсрәтләребезне алсаң иде. Коръәннән белмәгәннәребезне белергә, онытканнарыбызны искә төшерергә ярдәм итсәң иде. Иртәләрен һәм кичләрен даими Коръәнне укырга, аны аңлап, аның белән яшәргә насыйп әйләсәң иде. Кыямәт көнендә шушы китабыңны безнең өчен дәлил итеп, безгә каршы дәлил булудан сакласаң иде.

**ӘЙ, АЛЛАҺЫМ!** Син бөек көч-кодрәткә ия булучы Зат, Синең хөкемең һичшиксез безгә ирешә, карарың гаделдер. Синнән барча исемнәрең белән сорыймын. Син Үзеңне ул исемнәр белән атадың, яки Китабыңда иңдердең, яки мәхлукатларыңның берсенә белдердең, яки Үзеңдә яшерен гыйлем итеп калдырдың.

**Йәә АЛЛААҺ!** Син **Әль-ЌАУВИЙЙУ** — Син Көчле Зат. Син — Кодрәт Иясе. Синең куәтең җитмәгән бер эш тә юк. Сиңа бернәрсә дә авыр түгел. Нинди генә эш яисә хәл булмасын, аның өчен Синең “Күн” — “Бул“ дип әйтүең җитә һәм ул була.

**Син-Әль-МӘТИИНҮ —** Синең көчең-кодрәтең тулылыкка ирешкән. Сине бернәрсә дә зәгыйфьләндерә алмый. Эшләрне башкарганда Син беркемгә дә мохтаҗ түгел.

**Син – Әль-ГАЗИИЗҮ —** Син Көчле, Ќуәтле, изге Зат. Бөтен нәрсә Синең теләгең белән эшләнә. Син җиңелүгә дучар булмый торган Кодрәтле, Изге Затсың. Син - бөтен яктан Бердәнбер. Барчасы Сиңа чиксез мохтаҗ. Синнән башка һичбер нәрсә булмас.

**Син – Әль-ЌААДИРУ —** Син Үзең теләгән һәр нәрсәне эшләргә кодрәтле. Кодрәтеңнең чиге юк. Һәрнәрсәгә көчең җитә.

**Син – Әль –МҮЌЪТӘДИРУ —** Син һәрбер нәрсә каршында көч һәм куәткә ия. Җирдә көчле һәм кодрәтлеләр бар, әмма алар бөтенесе берләшеп Сиңа каршы чыкса да Сиңа тузан бөртеге кадәр дә тәэсир итә алмый. Синең каршыңда алар берни түгел.

**Йәә, Раббым!** Кулларымны күтәреп Сиңа дога кылам. Сиңа моң-зарларымны сөйлим, Синең ярдәмеңне өмет итәм. Син кулын күтәреп дога кылучының кулын буш калдырудан ояласың . Әй, Кодрәтле Аллааһ! Минем кулларымны да буш калдырма. Догаларымны кабул әйлә.

**Йәә, Раббым!** Безне динсезләр хөкеменә тапшырып, сынау кешеләре итмә. Безне күтәрә алмаслык сынаулардан, авырлыклардан сакла, төзәтә алмаслык афәтләрдән, дошманнарның зәһәрлегеннән сакла, коткар. Һәммәсенә Синең көчең, кодрәтең җитә.

**Йәә, Раббым!** Барча гамәл - гыйбәдәтләрне кылу өчен, намазларымны җиренә җиткереп, ихласлылык белән уку өчен, гаиләбездә вазыйфаларымны үтәү өчен җаныма тынычлык, тәнемә сәламәтлек, көч-куәт бир. Күңел төшенкелегеннән, шайтан зарарыннан, шайтан вәсвәсәсеннән, көчсезлектән, куркаклыктан сакла.

**Йәә, Раббым!** Безгә бүләк итеп биргән Ислам динендә гомеребезнең ахырына кадәр яшәргә насыйп ит. Тормышыбызны һәм дөньябызны безнең өчен хәерле кыл. Безгә дөнья һәм ахирәттә хәерлелек һәм бәхет бир. Чынлыкта, Синең һәрнәрсәгә көчең җитә. Уразамны җиренә җиткереп тотарга, гыйбадәтләремне ихласлык белән үтәргә көч, җиңеллек, куәт бир.

**Йәә, Раббым! Син – Әль-МӘЛИКҮ —** барча галәмнәрнең һәм Кыямәт көненең хакыйкый Патшасы. **Син – МӘЛИКҮ-Л-МҮЛК —** һәр нәрсәнең Иясе, Хуҗасы, Патшасы. Безнең бөтен малыбыз, байлыгыбыз — Синеке. Син байлыкны Үзең теләгән вакытта бездән аласың да, бирәсең дә. Безгә байлык бирсәң, шуның белән бергә сөенечен дә бир. Чөнки байлык булып, сөенече, бәрәкәте булмаса, аның файдасы юк. Безгә бәрәкәт ишекләрен ач.

**Йәә, АЛЛААҺ! Син – Әль-ВӘӘРИСҮ, Син – Әль-МҮЌЫЫЙТҮ.** Син - мал-мөлкәтнең һәм байлыкның, ризыкның Хуҗасы һәм аны без колларыңа юмартлык белән бүлеп Бирүче, мирас итеп Бирүче.

СИН - безләрне ризыкландырасың, күкләрдән шифалы яңгырларны яудырасың, корыган җирләрне терелтәсең, саргайган җирләрне яшеллеккә күмәсең. Безгә Син биргән нигъмәтләреңне күрә белергә, шөкер кылып , рәхмәтле булып яшәргә насыйп итсәң иде. Ул байлыкның үлемебез җиткән вакытта бер файдасы да булмаганын аңлап, нәфес колы булудан сакласаң иде. Булган мал - байлыгыбызны хәләл кәсеп белән табып, бәрәкәтен күреп, хәерле максатларда файдаланып яшәргә насыйп итсәң иде. Ашаган ризыкларыбызны хәләл ит, хәрәмнәрдән ерак кыл.

**Йәә, Раббым! Йәә МӘЛИКҮ! Йәә АЛЛААҺ!** Син һәр мәхлугыңа ярдәм бирүче. Йәә Раббым! Безне мохтаҗлыктан, ялкаулыктан, комсызлыктан, саранлыктан, вакчыллыктан саклый күр. Кешеләргә мохтаҗ итеп калдырма. Бурычлы булып калудан имин кыл. Бөек Кыямәт көнендә — кешегә малы һәм мөлкәте, байлыгы һәм акчалары да ярдәм итә алмаган көндә — мине һәм нәселемне Үзеңнең рәхмәтеңдә кыл.

*(Дәвамы киләсе санда.)*

**Фатыйма ФАТКУЛЛИНА һәм Эльвира ӘСӘДУЛЛИНА әзерләде.**

## Доганы түбәндәге тәртип буенча кылабыз

***1. Аллаһны мактап, Аның күркәм 99 исеме белән сорыйбыз.***

***2. Пәйгамбәребез с.г.в.с. гә күп итеп салаватлар әйтәбез.***

***3. Аллаһу Тәгаләнең биргән нигъмәтләренә шөкер кылабыз.***

***4. Гөнаһларыбызга истигъфар кылабыз, Аллаһның бөтен гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз.***

***5. Дөнья һәм ахирәт өчен хаҗәтләрне үзебез өчен сорыйбыз.***

***6. Әти-әниләребез, әби-бабайлар өчен сорыйбыз.***

***7. Гаиләбез һәм балаларыбыз, оныкларыбыз өчен сорыйбыз.***

***8. Укытучыларыбыз һәм остазларыбыз өчен сорыйбыз.***

***9. Ил башлыклары, җитәкчеләр өчен сорыйбыз.***

***10. Калган бөтен туганнарыбыз өчен сорыйбыз.***

***11. Күршеләребез, авылдашларыбыз, танышларыбыз өчен сорыйбыз.***

***12. Сыйныфташларыбыз, дусларыбыз, хезмәттәшләребез өчен сорыйбыз.***

***13. Мөселманнар, бөтендөнья мөселманнары өчен сорыйбыз.***

***14. Бөтендөнья халкы өчен, галәм өчен сорыйбыз.***



# Татар теленең сихри моңы

(Башы 13нче биттә).

— Нәнәй, кемнәр җырлый? — дип сорадым. Ул елмаеп:

— Әнә кортлар, балам, җырлый-җырлый эшли, — диде.

— Ә нәрсә диеп җырлыйлар? Мин җырлаган "Туган тел"не җырлыйлармы?

— Юк, Диләрә тизрәк акыллы булып үс, укырга өйрән, аннан безнең телне аңларсың, диләр, — диде нәнәй.

Ул вакытта миңа 4-5 яшь чамасы иде. Минем тизрәк үсәсем, укырга өйрәнәсем килде.

Икенче көннән үк Әлифбамны сумкама салып, нәнәйләргә укырга өйрәнергә йөри башладым. Укырга өйрәнү җиңел түгел икән, ләкин минем бал кортлары телен аңларга теләвем барсыннан да көчлерәк булып чыкты. Минем кечкенә йөрәгемә кошлар да, барлык бөҗәкләр дә туган телем — татар телендә сөйләшәләр кебек иде.Ә мин аларны аңлап бетермим әле.

— Нәнәй, сандугач нәрсә дип сайрый?

— Афәрин, Диләрә, укый белә башлады, дип сайрый, — диде нәнәй. Ә мин бу сүзләргә куанып, икенче көнне тагын да тырышыбрак укырга керешә идем. Нәнәем бигрәк тә хәйләкәр булган бит. Ул әле миңа табышмаклар уйлап килергә куша иде. Ә без әтием белән икәүләп уйлый идек.

— Кое дә бар, җыры да, баллы-татлы сые да, Даниярны чеметсә, аллы артлы сикертә. Ул нәрсә, нәнәй?

— Кем булсын, картәтиен. Үзе гармунда да уйный, матур итеп җырлый да. Безне бал белән дә сыйлый, ул инде, ул — Венер картәтиең.

— Дөрес түгел, нәнәй! Бал корты! Картәтиемнең бал кортлары.

Нәнәем минем күзләремә караган да, мут кына елмая.

Көн дә бакчага чыгуны дәвам итәбез. Кортлар телен аңлый башлаган кебек идем. Кортлар гына түгел, чәчәкләр дә татарча сөйләшә икән.

— Әнә кашкарыйлар, лаләләр сине мактыйлар. Безгә су да сибешә, безнең белән сөйләшер өчен укырга өйрәнергә тырыша, диләр, — дип әйтә иде нәнәй. Шулай булгач, ничек тырышмаска?!

Нәнәемнең әкиятләре дә гел татарча. Әкиятнең геройлары да шул ук бал кортлары, урман хайваннары, хәтта нәнәйнең казлары, кәҗәләре дә әкият геройлары иде. Алар да миңа гел күбрәк китап укырга кирәклеген әйтәләр, үзенең туган телен яраткан, телен яхшы белгән геройлар барлык авырлыкларны да җиңеп чыгуын аңлаталар иде.

Нәнәй бервакытта да нәрсәнедер көчләп такмый иде, ә күп укыган, туган телне яхшы белгән геройлар нәнәй әкиятләрендә уңышка очрыйлар иде.

Ә инде мәктәп бусагасын атлап кергәч, укытучым — әнием дә шул ук сүзләрне нәнәем сөйләгәнчә, тик азрак икенчерәк, Г.Тукай, А.Алиш, М.Җәлил, Ә.Еники, Р.Гарипов әсәрләре буенча аңлатыр булды.

Г.Тукайның шигыренә язылган җырны Финат абыем өч яшемдә өйрәткән. Өйрәнәсем килмәсә дә өйрәндем, чөнки абыемны бик ярата идем. Ничек инде яратмаска, кайткан саен тәмлекәчләр алып кайта, иң беренче алтын алкамны да ул алып бирде бит.

— "Туган тел" татарларның гимны ул.

Илдар абыем "Тәфтиләү"не баянда уйнап җибәреп, Финат абыем җырласа, алмагачлар, бал кортлары гына түгел, ә бар дөнья татар моңына төренгән кебек була иде миңа. Әнә шул моңны күктә йөзеп барган болытлар да туктап тыңлыйлар сыман иде. Ә миңа ничек тыңламаска да, ничек ул сихри моңны аңларга тырышмаска.

Болытлар дигәннән, әнә минем кебек бер кечкенә болыт, шул татар моңын тыңлап, әллә әнисен югалткан, бер тирәдә йөзә дә йөзә. Әллә мине күзәтә микән?! Нәнәем:

— Аның да синең кебек күп беләсе килә, синнән алдарак укырга өйрәнәсе килә, — ди. Шул болыттан артта каламмы соң, юк тырышырга кирәк. Нәнәй иртәгәгә шул болыт малае турында әкият уйлап килергә кушты. Хәзер кайтам да күзләремне чытырдатып йомып уйлап ятам. Мин шулай уйлаганда әллә нинди матур, маҗаралы уйлар килә.

Тагын бер яңа сүз ишеттем. Гимн. Аны да белергә кирәк.

Көз дә җитте. Әтием-әнием эштә, мин тагын да нәнәем-картәтием "мәктәбендәмен". Көндезге ашны ашагач, әкият тыңларга дип, нәнәем кочагына чумган идем, тыштан нindидер авазлар ишетелә башлады.

— Кызым, тор, безнең белән торналар хушлаша, — диде нәнәй.

Без йөгереп тышка чыктык. Чынлап та, һавада киртләч-киртләч юл салып, торналар оча, үзләре "тату торыйк", — дип кычкыралар. Ә иң арттан очып барганы "ачы-ачы" дигән кебек булды миңа.

— Әйе, кызым, туган ил, хәтта кошларга да якын, алар да үз туган яктан китәргә мәҗбүр итә. Шуңа да алар туган якны, туган илне ташлап китүләрен, "ачы-ачы", дип кычкыралар, — диде нәнәй. Миңә тагын яңалык! Кичә кыр казлары, рәт-рәт булып, тәртип саклап, "кыйгак-кыйгак" дип, киткәннәр иде, бүген инде торналар китә.

— Борыны озын, боты озын, камышлыкта көнозын, сазлыкларда ул йөри, "тату торыйк" дип көйли. Ул нәрсә, нәнәй?

— Мин җиңдем! Торна!

Бер көнне нәнәй миңа тагын бер сорау бирде:

— Кызым, нинди өч матур сүз беләсең?

— Мин яраткан иң матур сүз әнием, әтием, илкәем, — дидем.

Миңа калса, бар дөнья тик татарча сөйләшә иде. Икенче көнне нәнәйгә мин дә табышмак уйлап килдем. Минем кебек, ул да башын катырсын әле:

— Дүртенче сүз дә бар, кызым. Син аны беркайчан да онытма! Ул — туган тел. Безнең туган телебез — татар теле. Без Башкортстан татарлары, мәккәбез — Казан.

— Кызым, татар белән башкорт гомер буе күрше булып яшәгәннәр. Башкорт-татар уллары һәм кызлары да бердәм, тату булсын. Күрше хакы — тәңре хакы, ди халык мәкале. Бу мәкальне син дә онытма! Казан татарларыннан калышмаска, үзебезнең туган телебезне сакларга, якларга тиешбез. Ә күп белү өчен китапны яратырга, күп укырга кирәк. Татарлар горур, батыр халык. Әнә Мусалар хәтта үлемгә барганда да җырлап барганнар. Аның җырлары Моабитның таш диварлары эчендә тынмыйча, калын стеналарын тишеп чыгып бөтен дөньяга яңгыраган. Утларга-суларга салсалар да, чукындырсалар да, ассалар да, киссәләр да исән калган, баш имәгән горур татар теле, — ди нәнәй.

— Китап ул кара урман белән бер. Эченә кергән саен яңадан-яңа яңалыклар ачасың. Шул кара урман эченнән чыгу юллары да китапларда, — ди ул.

Бишенче сыйныфка укырга килгәч, мине татар әдәбиятыннан Альбина Рәзим кызы укыта башлады. Үскән саен карурман эченә ныграк керә башладык. Туган телемнең җир йөзендәге телләр арасында аралашу өчен иң аңлаешлы булган ундүрт телнең берсе икәнлеген белдем. Газиз телебезне ата-бабаларыбыз меңләгән еллар буена саклап, буыннан-буынга тапшыра килгәнен аңладым. "Кеше нихәтле күбрәк тел белсә, шулкадәр күбрәк белем алырлык сәләткә ирешә", — ди Альбина апа. Шуның өчен дә без үз телебезне — татар телен үзәккә куеп, шуның нигезендә башка телләрне өйрәнергә тиешбез. Альбина апа укучыларына энҗе бөртекләрен эзләп табу юлларын да өйрәтә.

Нәнәемнең бу сөйләменнән, үзебезнең Мәккәне — Казанны күрәсем килеп, хыял диңгезенә чумдым.

Нәнәйнең тагын да кызыклары бар әле:

Әйе, без татарлар дөнья картасының барлык почмакларында да яшибез, димәк бер җирлектә генә түгел. Безгә, татарларга, туган телебезне саклап калу өчен татулык та, бердәмлек тә кирәк.

Дөньяда иң матур тел — ул туган тел, ди халык. Әйе, халык бик дөрес әйткән. Шушы зур бәхетне югалтмас өчен без үзебезнең туган телебезне сакларга һәм ихтирам итәргә тиешбез. Туган телебезнең көче гаиләдә, әниләребезнең күкрәк сөтендә, нәнәйләрнең әкиятләрендә, шагыйрьләрнең матур-матур шигырьләрендә, үзәкне өздереп җырлаган җырларда сакланадыр ул, мөгаен.

Минем колакта нәнәем өйрәткән дүрт матур сүз: Әнием, Әтием, Туган ил, Туган тел!

— Кызым, бәхетне юлдан эзләмә, белемнән эзлә.



# Сыерчык оясы

**Рөстәмнәрнең бакча артында карт каен агачы бар. Бабасы аңа сыерчык оясы элгән. Оя, җил-яңгырда каралып, шактый таушалган, әмма шулай да һәр яз үзенә сыерчыклар кайта. Рөстәм аларны зарыгып көтеп ала. Сыерчыкларның төрле тавышлар чыгарып сайравына соклана. Я бака кебек бакылдый кошлар, я нәкъ кеше кебек сызгырып җибәрәләр.**

Көз җитте. Бәрәңгеләр алынды. Рөстәм дуслары белән бакча артына уйнарга чыкты. Кинәт көчле җил чыкты. Каендагы сыерчык оясы җиргә килеп төште. Рөстәм бертын берни аңламый торды, аннары кычкырып елый-елый өйләренә чапты.

Улын күрүгә, токмач җәйгән әнисенең кулыннан уклавы төшеп китте.

— Ә-ә-ә-ә-ни, сыерчык оясы, сыерчык оясы, сыерчыклар үлдеее...

Агарынып каткан, сүзен дә сөйли алмаган улын, әнисе ничек тынычландырырга белмәде.

— Аңламыйм бит сине, улым! Тынычлан әле бераз! Нәрсә булды?

— Ауды! Килеп төш-ттт-е а-а-агачччтан! Оя! Сыерчык оясы!

— Тынычлан! Синең башыңа төшмәгән бит! Әйдә чыгып карыйк!

Чәчелеп яткан ояны күргәч, әнисе улын кочагына кысты.

— Нәрсә өчен шулай өзгәләнәсең, улым?! Сыерчыклар һәлак булмаган ич. Алар күптән урманда, бәлки инде җылы якларга китәргә дә өлгергәннәрдер. Ә ояның яңасын әтиең кайткач ясарсыз. Тынычлан, ярыймы, акыллым. Бер генә кошчыкка да зыян килмәгән.

Әнисенә Рөстәмне бик озак тынычландырырга туры килде...

Әтисе Себердән кайту белән, Рөстәм аны оя ясарга ашыктырды.

— Улым, әле кыш, сыерчыклар иртәгә генә кайтмый! —дип тә карады әтисе. Тик Рөстәм аңа үзенекен тукыды.

Ояны бергәләп ясадылар. Язның матур бер көнендә карт каенга чыгарып элеп тә куйдылар. Хәзер инде язның беренче хәбәрчеләрен көтәсе генә калды.

Бүген ял көне, Рөстәм ишегалдына уйнарга чыкты. Бераздан тыны-көне бетеп чабып керде:

— Әни! Әни! Әни! Сөенче, безнең ояга сыерчыклар килгән! Кем сызгыра микән дисәм — сыерчык! Оядан чыгып сайрап утыра!

— Яңа ояга рәхмәт әйтеп сызгырган инде ул сиңа, — дип елмайды әнисе.

**Гөлназ ГАФАРОВА,**
**Краснокама районы Куян авылы мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.**

podpiska.pochta.ru

# “Игезәкләр-бизәкләр”

**Конкурс дәвам итә!**



**Динә һәм Ләйлә Рәхимовалар Уфа шәһәренең 84 санлы татар гимназиясендә 5 в сыйныфта укыйлар. Кызлар бик оста бииләр, иҗади эшләргә оста алар. Якты күңелле, алчак туташлар сабакташлары белән тиз үк уртак тел таптылар. Алар укуда тырыш, яңалыкка омтылып, мәктәп эшләрендә актив катнашып үсәләр.**

# Чын дуслар шундый була!



*Эльдар, Дана, Әким, Ясминә, Нурислам, Илназ Уфа шәһәренең 84 санлы Татар гимназиясе укучылары. 1 е сыйныфында укучы нәни дусларыбыз, укытучылары Айгөл Ахунова җитәкчелегендә, татар телен өйрәнүгә зур тырышлык сала.*

*— Гаиләбездә газетне яратып укыйбыз. Туган телебезне өйрәнүдә “Өмет” — “Чаткылар” зур ярдәмче безгә, — ди бу матур сабыйлар.*

## Тизәйткечләр

*Вак балыкны Шәвәли*
*Әвәли дә әвәли.*
*Әллә ваза ясыйсың? – ди*
*Авылдан килгән Вәли...*

*Ла-ла-ла-ла, ла-ла-ла,*
*Кем матур җырлый ала,*
*Кем матур бии ала –*
*Шул булыр үрнәк бала.*

## Без – татарлар!




Без — татарлар, телебез — татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул.

*Каюм Насыйри*

Мы — татары, наш родной язык — татарский, это самостоятельный и совершенный язык с четкими правилами.

*Каюм Насыри*

## Укытучыларга ярдәмгә

### Хайваннар һәм кошлар кайда яши?






Бу уен кыргый һәм йорт хайваннарының, кошларның исемнәрен истә калдыру өчен уйнала. Балалар алдына рәсемнәр элена. Укытучы сөйләшү үрнәкләре буенча сораулар бирә. Укучылар хайван яки кошларның кайда яшәве турында хәбәр итә.

*Мәсәлән: Куян кайда яши? — Куян урманда яши. Үрдәк кайда яши? — Үрдәк авылда яши.*

### Ул нинди?




Бу уен әйберләрнең билгеләрен дөрес билгеләү күнекмәләре өстендә эшләүне максат итеп куя. Укытучы балаларга төрле әйберләрнең рәсемнәрен күрсәтә, балалар аларның төп билгеләрен санап чыгарга тиеш.



*Мәсәлән, “Туп нинди? Туп зур (кызыл, яңа, чиста)”. “Алма нинди? Алма (ачы, тәмле, түгәрәк, яшел )”һ.б.*


**Мөхәррире — «Өмет»нең бүлек мөдире Алсу ГӘРӘЕВА.**



ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
8-986-978-51-50

**МӨХӘРРИРИЯТ:**
**Дилә БУЛГАКОВА — шагыйрә.**
**Әлфия БУЛАТ – шагыйрә.**
**Айгөл АХУНОВА — татар теле укытучысы, Башкортстанның атказанган укытучысы.**
**Лилия СӘГЫЙДУЛЛИНА – БДУның филология факультетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы доценты, педагогия фәннәре кандидаты.**


podpiska.pochta.ru

Өмет
Чаткылар
№11, 17 март, 2023 ел. 
*И туган тел,
и матур тел,
әткәм-әнкәмнең
теле!*
*"Өмет"нең балалар өчен газете*



# «Калфак – хатын-кыз матурлыгы билгесе»



*Калфагымның матурлыгын һәммәсе дә күрсеннәр: — Энҗе калфак кигән кыз ул —Татар кызы,— дисеннәр. (Р.Вәлиева)*

Калфак — үзенчәлекле хатын-кыз баш киеме. Элек аны татар туташлары һәм ханымнары бик яратып кигәннәр. Ул кешенең рухи матурлыгын, күңел байлыгын, тегү-чигү эшенә осталыгын, зәвыгын да чагылдырган, чөнки аны кызлар, кичләр утырып, серләшә-серләшә теккәннәр, аңа матур бизәкләр төшергәннәр, чиккәннәр. Шушы матур калфакларны бәйрәмнәргә, кунакка барганда кигәннәр. Бүген исә бу баш киемен күбрәк сәхнәдә, яисә бәйрәмнәрдә генә күрергә мөмкин. Хәзер гадәттә түбәтәй рәвешендә тегелгән кечкенә формасын кияләр, чәчкә каптыралар.

Халыкара хатын-кызлар бәйрәме алдыннан Краснокама районының Яңа Кабан авыл китапханәсендә өлкән сыйныф кызлары өчен Пушкин картасы буенча «Калфак — хатын-кыз матурлыгы билгесе» дигән осталык дәресе үткән. Башта китапханәче калфакның барлыкка килү тарихы, аның формалары, бизәлеше турында сөйләгән. Осталык дәресен актив китап укучы, матур шигырьләр авторы, аш-су, тегү-чигү остасы Сәфинә Шабутдинова алып барган. Сәфинә апа үзе калыплар ясаган, төрле материалларны «сынап», кибетләр буе чабып, бизәү өчен әйберләр хәстәрләгән.

Шулай итеп, бик матур калфаклар барлыкка килгән. Кызлар белән калфак әзерләү серләре белән уртаклашкан Сәфинә ханым. Өлкән сыйныф укучылары оста ярдәмендә үзенчәлекле калфаклар тегеп, һәркайсы үзләре тудырган кул эшен өйләренә алган. Бәлки, кызлар бу калфаклар белән сәхнәдә дә чыгыш ясар әле. Осталык дәресе барышында «Ак калфак», «Энҗе-мәрҗән калфагым... », «Кәләпүшем — калфагым» кебек җырлар җырлаганнар. Мондый очрашулар фәһемле дигән карарга килгән кызлар. Чөнки татар кызлары уңган да, оста да, тәрбияле дә булырга һәм үз милләтенең рухи кыйммәтләрен белеп үсәргә бурычлы.

**"Чаткы-инфо".**

**АРТЕМ СОЛТАНГӘРӘЕВ ЧАКМАГЫШ ГИМНАЗИЯСЕНДӘ 2 "А" СЫЙНЫФЫНДА УКЫЙ. ДҮРТЛЕ-БИШЛЕ БИЛГЕЛӘРЕНӘ ГЕНӘ ӨЛГӘШӘ. ИҢ ЯРАТКАН ДӘРЕСЛӘРЕ – МАТЕМАТИКА, ФИЗКУЛЬТУРА. ДУСЛАРЫ ДА КҮП. СЫЙНЫФТАШЛАРЫ КӘРИМ, КАМИЛ, ДАНИЛ БЕЛӘН ҺӘРВАКЫТ БЕРГӘ АРАЛАШЫП, НИНДИ ГЕНӘ ОЧРАКТА ДА БЕР-БЕРСЕНӘ ЯРДӘМГӘ КИЛӘЛӘР. Ә БИТ АЛАР УКУДА ГЫНА ТҮГЕЛ, "АРЕНА" БОЗ ШУГАЛАГЫНА ДА БЕРГӘЛӘП ЙӨРИ. МОНДА ДА ФИКЕРЛӘРЕ, КИҢӘШЛӘРЕ – УРТАК. ЮККА ГЫНА: "ДУСЛЫК – ФИКЕРДӘШЛЕК БЕЛӘН КӨЧЛЕ", – ДИМИЛӘР. "АФӘРИН!" ЯРЫШЛАРДА ЯУЛАГАН ҖИҢҮЛӘРЕ ӨЧЕН УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ БУ СҮЗЕН МАКТАУ ДИП КАБУЛ ИТӘ ХОККЕЙЧЫ МАЛАЙЛАР.**



# Уңышларны юлдаш итеп…

Җиде елдан артык эшләп килүче "Арена" боз шугалагы спортка мөкиббән райондашларыбызның иң яраткан урынына әверелде. Өлкән яшьтәгеләр дә, хоккей "җене" кагылган балалар да бирегә зур теләк белән йөри."Ястребы" — тәүге көннәрдән үк тупланган команда. Узган елда Бөтенрусия "Алтын шайба" клубы призына узган ярышларда 2009-2010 елгы балалар төркеме беренче урынны алуга иреште. Чакмагыш спортчылары районыбыз гына түгел, республика тарихында беренче тапкыр алтын биеклеккә күтәрелде. Русия чемпионнары бүген дә юлда, ярышларда сынатырга исәпләре юк.

*(Ахыры 14нче биттә).*



# Татар теленең сихри моңы

Хөрмәтле нәнәйләр, картәтиләр, әти-әниләр, бу хикәядә мин китап уку кебек мәдәниятне үстерү "энҗеләрен" яшердем. Сез аларны тапсагыз, балаларыгыз, оныкларыгыз туган телләрен яратырлар, татар милләтеннән булганнары өчен куанырлар, ә ул сезнең кулда диясем килә.

Чәчәкләрдән таралган хуш исне кибетләрдәге бер генә хушбуй да алыштыра алмас иде. Шушы матурлыкка сокланып, аларның гүзәллеген мактарга язгы җырчы кошлар да кушыла.

Май урталары иде. Бөтен дөнья ап-ак чәчәккә күмелгән. Алмагач, чияләрнең яфраклары да күренми. Бушлык табып, яфраклар башларын күтәрмәкче була, язгы кояш нурларында чәчәк бөреләре таҗларын ачып җибәрә. Ә инде яфракларга, үпкәләп, башларын ияргә генә кала.

Табигать нинди матур! Андый буяулар беркайда да юк, тик табигатьтә генә.

Табигатьнең шул мәлендә нәнәй мине бакчага алып керде. Умарталар белән мәш килгән картәтиемә чәй эчердек тә, үзебез хозурланып, масаеп утырган алмагачлар янына килдек. Алмагач янында бер моң колагыма ишетелде.

*(Ахыры 11нче биттә).*

podpiska.pochta.ru

# Шуңа күңелем шат минем...

**Кояш көлә, мин елмаям,**
**8нче Март бүген.**
**Бүген әниләр бәйрәме,**
**Шуңа күңелем шат минем.**
**(С.СӨЛӘЙМАНОВА)**



**Яз башы – җир йөзендәге иң сөйкемле затларны зурлаудан башлана. Яз һәм наз бәйрәме – 8 март елның иң гүзәл мизгеленә ишекләрне ача. Хатын-кыз гүзәллеге, әни назы җылыта да, иркәли дә, назлый да, яшәү көче бирә. Хатын-кызның бөтен матурлыгы Әни булуда дибез. Бу чынлап та шулай. Әни – илаһи зат, тормышта иң мөһим, иң кирәк, иң үрнәкле көч! Шуңа күрә һәр кыз балага, хатын-кызларга бу бөеклеккә ирешергә, Әни булырга, җылылык өләшеп, хөрмәткә коенып яшәргә насыйп булсын. Ә бүген, бераз соңлабрак булса да, әниләргә рәхмәт әйтәбез. Благовар районы Шырлык мәктәбе укучыларының әниләренә карата күңел түрләрендә нинди хисләр яши, күрегез, дуслар. Шикләнмим, бу халәт һәр балага хас. Кемнәрдер аны ачыктан-ачык әйтеп кенә бетерми. Ә 8 март көнендә һәр баланың күңеле шат була, шигырь юлларындагыча…**

*Минем әниемнең исеме – Раушания. Ул 1978 елда Таң авылында туып-үскән, урта мәктәпне тик якшы билгеләргә тәмамлаган.*

*Мәктәптә укыганда ул чаңгыда шуарга яраткан. Ярышларда катнашып, мактаулы урыннар да алган. Әдәбият дәресен яраткан, олимпиадаларда катнашкан.*

*Мәктәпне тәмамлагач, әнием Бәләбәй педагогия училищесына укырга кергән. Кулына диплом алып, үзебезнең районыбызга укытучы булып эшкә урнашкан. Күп тә үтми, әтием белән танышып, Шырлык авылына килен булып төшкән һәм балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә урнашкан. Минем әнием балаларны бик тә ярата. Үз эшен бик яратып башкара. Мин дә әниемне бик нык яратам, хөрмәт итәм. Исән- сау булуын телим.*

**Әминә ӘЮПОВА,**
**8нче сыйныф.**

*Минем әнием Кушнаренко районының Казарма авылында туып-үсә. Бүгенге көндә әтием белән Благовар районының Шырлык авылында матур итеп дөнья көтәләр.*

*Һәр кеше өчен үз әнисе – иң ягымлысы, иң матуры, иң уңганы. Минем әнием дә шундый. Аның исеме Гүзәл. Ул башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшли. Әниебез безне – мине һәм бәләкәй туганымны тәрбияли. Без барыбыз да аны бик яратабыз. Әнине бер кеше белән дә алыштырып булмый. Чөнки ул безгә яшәү бәхете бүләк иткән. Баласы өчен янып-көеп, төннәр буе йокламыйча тәрбияләгән. Баласы итәгатьле кеше булып үссен өчен гомер буе тырыша әни кеше. Шуның өчен без әниләребезне кадерләп яшәргә тиешбез.*

**Диләрә ӘМИРОВА.**

*Әни! Нинди ягымлы да сүз ул! Әни өйгә килеп керү белән, өй яктырып китә. Әни үзенең карашы белән дә безне һәр яктан саклый һәм яклый кебек.*

*Һәр балага үз әнисе кадерле һәм якын була. Мин әниемне бик нык яратам. Аның исеме –Зөһрә. Ул бөтен эшкә дә уңган. Әтием белән 5 бала тәрбиялиләр. Әнием безне тырыш булырга, яхшы укырга, ялкауланмаска өйрәтә. "Эшләвегез кеше өчен булса, өйрәнүегез үзегез өчен", – ди ул.*

*Әни, син безгә бик кирәк, гел шулай матур булып кал! Балаларыңны, оныкларыңны шатландырып яшә.*

**Зәлия РИЗВАНОВА.**

*Әни – җирдә иң газиз, якын кеше. Ул сине тудырган, көйләп бишектә тирбәткән, синең беренче елмаюыңны, беренче сүзләреңне ишетеп сөенгән, тәпи атлап китүеңне күреп шатланган. Ул безне туган телебезне яратырга өйрәткән. Без үзебезнең тормышыбызны әниләрдән башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Алар – безнең дөньябызның яме, шатлыгы. Һәр кемгә үз әнисе дөньядагы иң кадерле кеше булган кебек, миңа да үз әнием бик кадерле.*

*Барлык балаларныкы кебек, минем дә телем "әннә", "әни" сүзе белән ачылган. Әнием минем бик сабыр, тыйнак кеше. Әниемнең исеме Гүзәл. Бу исем төрки теленнән кергән. Ул: "матурлык" дигәнне аңлата. Әниемнең йомшак куллары, ягымлы тавышы миңа шатлык китерә. Мин әниемә кулымнан килгәнчә булышырга, аны борчымаска тырышам. Әнием миңа дәресләремне эшләргә дә булыша: аңлашылмаган сорауларыма да сабыр гына җавап таба, файдалы киңәшләрен дә бирә. Мин мәктәптән кайтуга, әнием инде тәмле-тәмле ризыклар пешереп куярга дә өлгергән! Без аның белән тәмләп чәй эчәбез, серләребез белән уртаклашабыз.*

*Ял көннәрендә без саф һавада йөрергә яратабыз. Әнием мине һәр кичне назлап йоклата, ә иртән "кызым" диеп, сөеп уята. Нинди зур бәхет! Ярый әле, әнием, янәшәмдә син бар! Әнием, мин сине бик яратам! Сиңа иң изге теләкләремне генә телим.*

**Диана ШӘЙМӨХӘМӘТОВА.**

# Уңышларны юлдаш итеп…

**(Башы 13нче биттә).**

Артем да бәләкәй чагыннан ук тимераякта шуарга яраткан. Боз шугалагына йөри башлаганда аңа нибары дүрт яшь булган.

– "Арена"га мине әтием алып барды. Монда миңа нык ошады. Азат Илшат улы үткәргән күнекмәләрне көтеп алдым. Ул – иң яхшы тренер. Беренче көннәрдән үк безне үз өстеңдә эшләргә, команда өчен җаваплы булырга өйрәтте. "Ястребы"да иң кыюлар, җитезләр тупланган. Боз өстенә чыкканнар җиңү өчен бөтен көчен, тырышлыгын сала. Минемчә, спортны яратканнар бервакытта да югалып калмый, һәрвакыт җиңүгә омтыла."Уеннарда уңышсызлыклар була икән – аны кабул итә белергә кирәк", – дип киңәшләрен бирә безнең тренерыбыз.

Февраль ае азагында "Ястребы" командасының 2014 елда туган балалар төркеме Удмуртия Республикасының Можга шәһәрендә үткәрелгән "Бәллүр шайба" турнирында катнашты. Өч көн дәвамында 7 команда алкалы хоккей буенча көч сынашты, һәр гол өчен ярышлар кызу барды. Шәһәр командалары арасында безнең Чакмагыш авылы хоккейчылары бердәмлекләре, җитезлекләре белән аерылып торды, призлы урын алуга иреште. Артем Солтангәрәев иң оста бомбардир булып танылды. Уен азагында ул телевидение хәбәрчесенә интервью да бирде. Җаваплары кыска, әмма бик анык булды.

Яшь хоккейчының беренче бүләге генә түгел бу. Спорттагы уңышлары хакында төрле ярышларда яулаган Кубок, медальләре һәм грамоталары бик ачык сөйли. Аларны санап чыгу да бик күп вакытны алыр иде. Сигез яшьлек малай җитезлеге, өлгерлеге белән турнирларда иң яхшы снайпер, иң оста бомбардир булып билгеләнгән.

– Кайда гына булсак та, уен тәмамлану белән әниемә-әтиемә шылтыратам. Аларның безнең белән бергә барган чаклары да бар.

Сүз дә юк, ата-аналар баласының уңышларына сөенеп яши, алар өчен мөмкин булганның барын да эшләргә тырыша. Алар өчен иң мөһиме – газизләре сәламәт, чыныккан булсын.

Артемнын әнисе Альбина – шәхси эшкуар. Әтисе Илшат вахта ысулы белән Себердә эшли. Апасы Алсу алтынчы сыйныфта укый. Гаиләдә шундый акыллы, ипле, тыңлаучан малай үсүе – бәхетләрнең иң олысыдыр, мөгаен. "Аның укудан тыш вакытын файдалы итеп үткәрүенә бик канәгатьбез", – ди якыннары. "Оныгыбыз – горурлыгыбыз",- дип сөенә нәнәсе белән картәтисе дә.

Игътибар иткәнегез бардыр, спорт белән дус булганнарның күңелләре һәрвакыт шат, алар елмаеп, күтәренке кәефтә йөри. Дуслары белән аралашалар, буш вакытларында якыннарына кулларыннан килгәнчә ярдәм итәләр. Һәм инде якты, матур хыяллар белән яшиләр. Артем да киләчәк тормышын хоккейдан башка күз алдына да китерми икән.

– Миңа әле укырга да укырга. Мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлап, югары белем алып, алкалы хоккей буенча тренер булып эшлисем килә. Таләпчән, яхшы остазым Азат Илшат улы кебек.

Хоккей уйнарга теләге булган кызлар-малайлар өчен "Арена" боз шугалагының ишекләре һәрвакыт ачык. Ә инде боз өстендә күз иярмәслек тизлектә шайба куган малайларга яңадан-яңа унышлар, алтын биеклекләр юлдаш булсын, барысының да хыяллары чынга ашсын. Ышанычыбыз зур: Артем кебек боз хуҗалары – яшь хоккейчыларыбыз районыбыз данын еракларга таратыр әле. Җилдән җитез яшь спортчыларыбызга уңышлар гына телибез!


**Мөнирә ӘНВӘРОВА.**
Чакмагыш районы.

# КРОССВОРД

1 нче сыйныф укучысы Радмир Ильясов төзегән кроссвордта кошлар яшеренгән.

Аларны дөрес итеп язып чыксагыз, ачкыч сүздә шулай ук канатлы дустыбызны табарсыз.

**Уфа шәһәренең 84 санлы Татар гимназиясе укучысы.**



podpiska.pochta.ru



# Ятимлек ярасы



**СУГЫШ... КҮПМЕ САБЫЙНЫҢ ЯЗМЫШЫНА ҮТЕП КЕРЕП, ӨМЕТ-ХЫЯЛЛАРЫН ЧЕЛПӘРӘМӘ КИТЕРГӘН, БАЛАЧАК БӘХЕТЕННӘН МӘХРҮМ ИТКӘН СҮЗ... ЯТИМЛЕК АЧЫСЫН ДА ТАТЫГАННАР, АЧЛЫК БЕЛӘН ДӘ КҮЗГӘ-КҮЗ ОЧРАШКАННАР. ТИК ТОРМЫШТА НИКАДӘР АВЫРЛЫКЛАР КҮРСӘЛӘР ДӘ, АЛАР СЫНМЫЙЧА, СЫГЫЛМЫЙЧА ЯШӘҮЛӘРЕН ДӘВАМ ИТӘЛӘР. Ә КҮҢЕЛЛӘРЕНДӘ БЕР ГЕНӘ ТЕЛӘК: «СУГЫШЛАР КАБАТЛАНМАСЫН».**

Мин гаиләм белән Дәүләкән районы Чуенчы авылында 1984 елдан бирле яшим. 2019 елда мине Чуенчы авыл советының ветераннар оешмасына рәис итеп сайладылар, шул вакыттан мин ветераннарның биографияләрен, тормыш юлларын өйрәнә башладым. Һәрберсенең тормыш юлы катлаулы, чөнки алар сугыш чоры балалары бит. Сугыш аларны ятим итеп, балачакларсыз, күпләрен әти-әнисез дә калдырган.

Шундый пенсионерларның берсе — Миңнихан Вәгыйз улы Сафин — гыйнвар аенда үзенең 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Шул уңайдан, без Чуенчы авылы советы башлыгы С.Н. Никифоров һәм ветераннар оешмасының әгъзалары белән аны матур юбилее белән котладык.

Миңнихан Вәгыйзь улы 10 яшеннән ятим кала. Өч ир туганы белән төрле балалар йортларында тәрбияләнә. Тумыштан сау-сәламәт булган бала, балалар йортында, йогышлы авыру аркасында (корсак тифы), гарип булып кала. Аның уң аягы кыскара, атлап йөрүе кыенлаша. Ләкин ул төшенкелеккә бирелми, укырга, яшьтәшләре белән аралашырга тырыша. Озак та үтми, аның өлешенә тагын бер сынау килә: ул тагын яшәү белән үлем арасында кала. Балалар йортында башка балалар белән уйнап йөргәндә, аның өстенә кирпеч стена ишелеп төшә. Тәрбиячеләр, бу бала үлгәндер инде дип уйлап, аның исән калуына ышанмыйлар...

1959 елда сыйныфташ кызы Фәридә белән гаилә коралар. Башта Дәүләкән районының Алга авылында яшиләр, берничә елдан Чуенчы авылына күченеп кайталар.

Фәриданең әнисе баштарак кызының гарип егет белән тормыш коруын өнәп бетермәсә дә, соңыннан киявен үз улы кебек ярата башлый. Миңнихан гарип булуына карамастан, акыллы, уңган, тырыш, намуслы, игелекле кеше булып чыга.

1965 елда уллары Рәфис дөньяга килә. Гарип кешедән нинди бала туа икән дип ул баланы күрергә бөтен авыл килә. Килүчеләр арасында яшь гаиләнең бәхетенә сөенеп, “бәбәй чәе" алып килүчеләр дә була. 1968 елда икенче уллары Рөстәм, 1971 елда кызлары Гөлнур туа.

Миңнихан Вәгыйз улы гариплегенә карамый беркайчан да эшсез утырмый: колхозның көтүен дә көтә, машина-трактор паркында каравылчы да булып эшли, авылдашларының киез итекләрен һәм аяк киемнәрен төзәтеп бирә.

**ФӘРИДӘНЕҢ ӘНИСЕ СОҢЫННАН КИЯВЕН ҮЗ УЛЫ КЕБЕК ЯРАТА БАШЛЫЙ. МИҢНИХАН ГАРИП БУЛУЫНА КАРАМАСТАН, АКЫЛЛЫ, УҢГАН, ТЫРЫШ, НАМУСЛЫ, ИГЕЛЕКЛЕ КЕШЕ БУЛЫП ЧЫГА.**

Беркайчан да чире аркасында килеп чыккан авырлыкларга зарланмады, 72 яшендә үлеп киткән тормыш иптәшен югалтуын авыр кичерсә дә, 15 ел инде ялгыз яши. 2019 елдан Дәүләкәндә Гөлнур кызы янында яши. Һәрвакыт елмаеп торучы Миңнихан абыйга карыйм да, тормыш авырлыкларын җиңеп чыгар өчен күпме көч тапкан үзендә димен. Чын йөрәкле, тормышны ярата белгәне өчен рәхмәт аңа.

**Розалия ГАЛИЕВА,**
**Чуенчы авыл советы ветераннар оешмасы рәисе.**



## Исән-сау әйләнеп кайтыгыз!

*Тугыз еллап гади украинлы*
*Кол хәлендә туган илендә.*
*“Слава Украине!" дигән лозунг*
*Хаин бандеровчы телендә.*

*Үз халкын илендә җәберләүче,*
*Җинаятьче булмый, кем булсын.*
*Байден кушканнарны үтәүчедә*
*Башка юньле нинди уй тусын.*

*Украина өчен сәясмәннәр*
*Көнбатыштан “ярдәм" озата.*
*Шушы миномётлар Донбасстагы*
*Шәһәр йортларына төз ата.*

*Иминлекне саклау канга сеңгән.*
*Буыннардан, ата-бабадан.*
*Ватан алдындагы изге бурыч*
*Үтәлергә тиеш яңадан.*

*Өстегезгә хәрби кием киеп,*
*Паёкларны салып рюкзакка,*
*Горур атлап, рух ныклыгы белән*
*Юлландыгыз алгы сызыкка.*

*Туган яклар калды еракларда,*
*Намусыгыз юлга чакырды.*
*Исән-сау әйләнеп кайтыгыз, дип,*
*Сәлам юллыйм сезгә ялкынлы.*

*Яшь буынга үрнәк булып тора*
*Сез күрсәткән кыю батырлык.*
*Яу кырында кылган геройлыклар*
*Тарих битләрендә калырлык.*

*Үз халкына кул күтәргән затка*
*Аллаһ бирсен гадел җәзасын.*
*Буыннарда ата-ир, улларга*
*Күрсәтмәсен сугыш газабын.*

*Җиңү көне якынлаша бара,*
*Алга дәшә биргән антыгыз.*
*Туган илгә, туып-үскән җиргә*
*Исән-сау әйләнеп кайтыгыз!*

**Дамир ВӘЛИЕВ.**
Бүздәк районы, Таулар авылы.

podpiska.pochta.ru

“Өмет һәм мин” 100 безгә

2014 ЕЛ МӘДӘНИЯТ ЕЛЫ БУЛАРАК ИГЪЛАН ИТЕЛГӘЧ, БЕЗДӘ ӘЛЕГЕ ЕЛ УҢАЕННАН “МӘДӘНИ УЧАК” АКЦИЯСЕ КЫСАЛАРЫНДА “ӨМЕТ” ГӘЗИТЕ КОЛЛЕКТИВЫ БЕЛӘН КҮРКӘМ ОЧРАШУ УЗГАН ИДЕ.

## Очрашуыбыз — матур хатирә



“Безнең Бадрак авылы халкы үз туган телен яратып, мәдәниятне баетып, гәзит-журналлар укып яши. Укыйлар да, иҗат итүчеләр дә байтак. Ә иҗат иткән кешеләр өчен гәзит-журналлар аеруча кирәк. Авылыбызда матур, сәләтле, өметле, туган телле яшь буын үсеп килә. Безнең шундый эчтәлекле, матур гәзитне чыгаручы хезмәткәрләрнең үзләре белән якыннанрак танышасы килә. Килегез әле безгә кунакка. Безнең сәләтле авылдашларның уңышларын да күреп китәрсез” дигән сүзләр язып, моннан 9 ел элек “Өмет” редакциясенә хат җибәргән идек.

Ниһаять, матур яз аенда кунакларыбыз авылыбызга килеп тә төште. Үзләре белән редакциянең күптәнге дусты, җырчы һәм гармунчы Салават Әхсәновны да ияртkәннәр иде. Кунакларны икмәк-тоз белән каршы алдык. Кул эшләре осталарының күргәзмәсен дә оештырдык. Бездә осталар җитәрлек. Альбина Нафыйкова, Римма Әхмәтҗанова, Нәфисә Хәбибдиярованың иҗат җимешләре күргәзмәне бизәде. Кунаклар клубның икенче катында урнашкан китапханә белән дә танышып чыктылар. Китапханәче Мөнзилә Садыйкова интернет заманы хакимлек итсә дә, һәр укучыны китаплар сайларга, үзара аралашырга, вакытлы матбугат белән танышырга җәлеп итә. Үзебезнең шагыйребез дә бар — Фаек Мөхәммәтҗанов. Талант иясенең шигырьләрен һәркем яратып укый.

Очрашу вакытында сәхнәдә якташ җырчы-гармунчы Салават Әхсәнов белән бергә авылыбыз талантлары Гөлнара Зарипова, Лида Әхмәтҗанова, Эльвира Хәсәнова, Лиза Фәттахова, Эльберт Хаҗиев, Резидә Әхмәтшина кебек биюче һәм җырчыларның чыгышларын да зур алкышлар белән каршы алдылар. Мәдәният йорты җитәкчесе Фәридә Сәгъдиева оештыруында бәйрәм концерты гөрләп узды. Үзем җитәкләгән “Гөрләвекләр” бию ансамблендә шөгыльләнүче егетләр-кызлар да сәләтләрен күрсәтте. Бу көнне алтын туйларын билгеләүче Нәҗметдиновлар һәм Ягәфәровлар да хөрмәтләнде.

“Өмет” гәзите редакторы Рәдис Ногмановның, аның урынбасары Гүзәл Гаянованың ихлас чыгышлары чараны тагы да баетып җибәрде. “Өмет”челәр белән якыннан танышу, аралашу бәхетенә ирешеп, киләчәктә дә гәзит белән дустанә мөнәсәбәтне саклау һәм ныгыту теләге белән таралыштык.



Менә ничә еллар яраткан гәзитебезне алдырабыз, укыйбыз, аннан аерылганыбыз юк. Иҗади коллективка алга таба да илһамланып, чәмләнеп эшләүләрен телим. Бергә булыйк, бердәм булыйк.

**Гөлнара САБИРОВА.**
Борай районы
Зур Бадрак авылы.

# Авыл уеннары

**“АЕК АВЫЛ” КОНКУРСЫНЫҢ МУНИЦИПАЛЬ ЭТАБЫНДА КАТНАШКАН 1200 АВЫЛНЫҢ 54Е РЕСПУБЛИКА ЭТАБЫНА ЧЫКТЫ. ҺӘРКАЙСЫ ҮЗ АВЫЛЫН РЕСПУБЛИКА КҮЛӘМЕНДӘ КҮРСӘТӘСЕ КИЛӘ. КУШНАРЕНКО РАЙОНЫНЫҢ “ЮГАРЫ КУЛЬТУРАЛЫ АВЫЛ” ИСЕМЕНӘ ЛАЕК БУЛГАН ИСКЕ ГОМӘР ДӘ ФИНАЛГА ЧЫГУЧЫ 54 АВЫЛ ИСЕМЛЕГЕНДӘ. КҮПТӘН ТҮГЕЛ АЛАР АВЫЛ УЕННАРЫНА – КЫШКЫ САБАНТУЙГА ҖЫЕЛДЫ.**



Уеннарда катнашырга, авылның бу югары исемгә лаеклымы-түгелме икәнлеген карарга мәртәбәле кунаклар: Бөтендөнья башкорт корылтае халыкара иҗтимагый оешмалар союзы аппараты җитәкчесе Рөстәм Сәлим улы Баянов, Кушнаренко районы советы сәркәтибе Айвар Әхнәф улы Тангатаров, Кушнаренко районының мәгариф бүлеге җитәкчесе урынбасары, Бөтендөнья башкорт корылтаеның Кушнаренко районындагы башкарма комитеты рәисе Ильвира Нәзит кызы Сахаува килделәр.

Кунаклар авыл белән таныштылар, Бөек Ватан сугышында башын салган авылдашлар истәлегенә обелискка чәчәкләр салу тантанасында, мәдәният йортында үткән “Мин бу җирне матурларга тудым” дип исемләнгән буыннар очрашуында катнашты.

— Мин бүген көн дәвамында берьюлы биш чарада катнаштым, - диде үз чыгышында Рөстәм Сәлим улы. Ул “Аек авыл” конкурсы, аның шартлары турында тәфсилләп сөйләде.

Иске Гомәр авылында 500гә якын кеше яши. Ун ел элек авылда урта мәктәп ябылган, авыл балалары күрше Чишмә районының Бишкәҗә авылына йөреп белем ала. Авылдагы балалар бакчасында 17 бала тәрбияләнә, фельдшер-акушер пункты, мәчет эшли. Кунаклар, шулай ук, авыл кибете белән дә таныштылар.

— Локмановларның кибетен мин “Авылмаркет” дип атар идем, — ди Рөстәм Сәлим улы. — Хәтта “Леруа” яисә “Окей” кибетләре белән чагыштырырга була аны. Локмановлар гаиләсе “Атайсал” проекты кысаларында да изге эшләр башкара икән: авыл халкының яратып барган Карама тавының башына агачлар утыртып, төрле аллеялар ясауны оештырганнар. Әлеге вакытта Гашыйклар паркы, Яшьләр аллеясе барлыкка килгән. Алар бу эшне киләчәктә дә дәвам итәргә хыялланулары әйтте.

Катнашазык чыгаручы цехта булдык, алар авыл хуҗалыгын югары аксымлы комбикорма продукция белән тәэмин итәләр. Анда 17 кеше эшли, бу авылдагы кешеләрне хезмәт, эш хакы белән тәэмин итүдә зур адым.

Рөстәм Сәлим улы авылда алып барылган патриотик эшне дә югары бәяләде, әлеге эшне оештыручыларның барсына да рәхмәт әйтте.

“Мин бу җирне матурларга тудым” дип исемләнгән буыннар очрашуында бик озак еллар бергә гомер иткән гаиләләр белән матур итеп яшәп ятучы яшь гаиләләр очрашты. Олылар “Алга” колхозының гөрләп торган чакларын, авылны төзекләндерүгә күп көч салган җитәкчеләр, бүген инде ахирәттә булган Хисматуллин Ханиф Хатмулла улын, Миргалиев Ринат Хатмулла улын, Сәлимуллин Рәсил Мәхмүт улын рәхмәт сүзләре белән сагынып искә алдылар. Очрашуга килгән Кәүсәрия апа белән Газим абый Могаттаровлар, Шафика апа белән Галләм абый Гыйләҗевлар, Рәзимә апа белән Тәлгат абый Ахуновлар, Бөек Ватан сугышы ветераны Әнәс абый Әхмәдиев (тормыш иптәше Зилә апаны ике ай элек кенә соңгы юлга озатты), Саимә апа белән Наил абый Могаттаровлар сәхнә түрендә балкып утырды. Дамира һәм Айрат Локмановлар, Нурзилә һәм Илфиз Җиһангировлар, Фәнидә һәм Айваз Сәлимуллиннар гаиләләре дә музыкаль күчтәнәчләре белән сөендерделәр.

“Авылның йөрәге тибә, аек авыл — ул җанлы авыл”, — дип нәтиҗә ясады Корылтайдан килгән кунак.

Очрашудан соң урамда кунаклары һәм авыл халкын тәмле пылау көтә иде. Самавырда кайнаган мәтрүшкәле чәйләр эчеп тамак ялгап алгач, уеннар башланды. Чүлмәк вату, капчык сугышы, авызга йомыркалы кашык кабып, көянтәле чиләкләр белән йөгерү һәм башка уеннар уйнадылар. Мөхтәрәм кунаклар да читтә калмады: Рөстәм Сәлим улы күзләрен бәйләп чүлмәк ватты, Ирина Зәлиф кызы белән Ильвира Нәзир кызы көянтәле сулы чиләкләр белән йөгерде.

Борынгы уеннарның иң кызыгы — көрәш. Авыл батыры Денис Сәлимуллин көрәштә җиңеп, тәкә алды.

**Эльвира ӘСӘДУЛЛИНА.**





# Ришат өйләнә

**Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган артисты Ришат Төхвәтуллин өйләнә.**

Җырчы сөйгәненә тәкъдим ясаган. Булачак кәләш - Ришат төркемендә эшләүче Алия Карачурина. Алар турында имешмимешләр күптәннән йөрсә дә, яшьләр бер-берсенә булган хисләрен халыкка ачыктан-ачык күрсәтмәделәр. Кызга тәкъдимне Ришат Уфада концерт куйганнан соң, кафеда туган көнен билгеләгәндә ясаган. Бу видео интернет киңлекләрендә яшен тизлегендә таралды. Кадрларда икесенең дә дулкынлануы, Алиянең шатлыктан елавы күренә. "Бу клип түгел. Ул "Әйе" диде", дип язган Ришат видео астына. — Күпләр минем җырларда җырланган мәхәббәтемне тизрәк табуымны теләде. Ә ул һәрвакыт минем янымда иде", — дип уртаклашкан җырчы. Алия исә: "Без Ришат белән бик озак очраштык. Беренче тапкыр "свидание"гә ул мине 2015 елның 10 июнендә чакырган иде. Бу вакыт эчендә нәрсә генә булмады. Ә хәзер без бер-беребезгә яңадан гашыйк булып, барысын да өр-яңадан башлыйбыз сыман", — дигән.

Җырчы никах һәм туй көннәрен билгеләүләре турында да әйткән."Аллаһы боерса, барысын да күрерсез, белерсез. Без хәзер берни дә яшермибез", — дигән ул.

Ришат белән Алиягә саф хисләрен картлыкка кадәр саклап, бәхетле яшәүләрен телибез!



# "Тавышы һаман шул ук"

**Бөтендөнья татар конгрессының матбугат хезмәте һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү идарәсе җитәкчесе Гөлназ Шәйхи социаль челтәрдәге сәхифәсендә Флёра Сөләйманова белән очрашудан видео куйган.**

"Татарстанның халык артисты, яраткан җырчыбыз Флёра апа Сөләймānованың туган көне. Аңа 84 яшь тулды. Аны котлап, хәлен белеп кайттык", — дип язган ул.

— Бүген сезнең бәйрәм, күңелегездә нинди хисләр" — дип сорый Гөлназ ханым җырчыдан.

— Аллага шөкер! Елыйсы килеп китте. Каян нинди хис булсын инде сиксәнгә җиткәч, сиксәннән узгач. Яшьне санамыйча булмый инде", — ди Флёра Сөләйманова.

Тамашачылары видео астына: "Яшь бара инде ул, нишләтәсең. Тавышы һаман шул ук, җанны иркәли", "Менә рәхмәт сезгә, күрәсе килгән иде", "Сөбханалла, тавышы һаман челтәрәп тора. Флёра апага исәнлек, тынычлык, гомере рәхәттә узсын. Матур тавышлы җырчыбызның җырларын күп тыңладык. Рәхмәт", — дип, матур теләкләрен калдырганнар.

# "Бу "пиар" түгел!

**«Син – минем кадерлем, мин – синең бәгырең, мәхәббәт шушыдыр, шушыдыр" дип җырлаучы Лилия Хәмитовага җырчы Винарис Ильегет тәкъдим ясаган.**

Бу хакта Винарис Ильегетнең туган көненә багышланган кичәдә билгеле булды. Видеода: "Бу уен да, спектакль дә түгел", — ди Винарис. Лилия исә: "Мин риза, риза", — ди. Винарис аңа бөтен кунаклар алдында йөзек белән чәчәк бәйләме бүләк итә.

Күпләр моңа ышанмады, кызык булсын өчен генә спектакль уйнаганнар дип уйлыйлар. Винарис үзе исә: "Без Лилия белән һәрвакыт бик якын дуслар булдык. Ләкин менә дуслык көтмәгәндә генә мәхәббәткә әверелде. Күп кеше моны "пиар" дип уйлый. Әмма бу "пиар" түгел", — дигән.



Лилия:

— Бу хакта уйлаганым да юк иде. Кая инде ул кияүгә чыгу?! Әни авырый, улым өченче курста укый. Тормыш мәшәкатьләре баштан ашкан. Мин бит аны энекәшем кебек кабул иттем. Без аның белән бик күптәнгә танышлар. Дуслыгыбызга егерме елдан артык инде. Тик шулай да, эшләр болай тирәнгә китәр дип уйламадым. Винарис тәкъдим ясагач, шок хәлендә калдым. Әни дә, нишләвең бу дип, шаккатты. Улың да бар ич синең дип, акылга китерергә тырышты. Улым Әмиргә әйткәч, "Әни, ә нәрсәдән куркасың?" — диде. Чыннан да, ә нәрсәдән куркам соң мин? Инде менә күпмедер вакыт узды, менә бу халәт ошый дигән фикергә килдем әле. Тәкъдим ясадылар да, чыгып киттем дигән сүз түгел инде, ә кәләш

Ләйсән КАСПРАНОВА әзерләде.

# Урзайбашлар бәйгедә узышты



Март башында авылыбызда күңелле спорт чарасы узды. Авыл халкы бу көнне зур әзерлек белән түземсезләнеп көтеп алды.

Авылдашларыбыз бердәм, сәләтле һәм тырыш безнең. Бу көнне дә ак кар өстендә дә сый-нигъмәт тулы табыннар корылды, самавырлар кайнар пар бөркеп кайнап, халыкны чакырып торды, теләгән һәр кеше сыйланды, аралашты. Бәйрәм күптән очрашмаган якташларны, сабакташларны, туганнарны бергә җыйды, авылдашларны якынайтты, илебез өчен катлаулы вакытта бердәмлеккә, берләшүгә сәләтле булуыбызны танытты. Бу көнне бер минут тын калып, без авылыбызның асыл егете, махсус хәрби операциядә һәлак булган Фируз Миннебаевны искә алдык...

Ярышлар күңелле җыр-моңнарга уралеп дәвам итте. Авылыбызның тугры балалары — Альбина һәм Илдар Шәриповлар халыкка матур җырлар бүләк итте. Гомумән, Шәриповлар турында туган якның патриотлары дип шикләнми әйтеп була. Алар авылда узган һәр чарада катнашып, балаларга Яңа ел бәйрәмнәре оештыруда үрнәк күрсәтәләр.

Чаңгы ярышлары зур дәрт белән чәмле узды. Аның зур энтузиазм белән узуын хөкемдар аерым атап үтте: укучылар һәр ярыш төрендә дә тик яхшы нәтиҗәләр генә күрсәттеләр.

Кышкы сабантуйга әверелгән бу бәйрәмдә көянтә белән су ташу, аркан тартышу, тюбингларда узышулардан соң, кар өстендә футбол, уйнап, чаңгыларда ярышып уздык. Ярышларны исә барыбыз да көтеп алган скандинав йөреше белән тәмамлап куйдык. Күпчелек авылдашларның, чакырылган кунакларның бер булып шушы йөрештә узуы ямьле мизгел булып истә калды, кәефләребезне тагын да күтәреп җибәрде. Урзайбашлылар авылны саклау өчен һәр көнебезне матур һәм мәгънәле эшләргә багышлап яшибез.

**Лена ГЫЙМАЛЕТДИНОВА.**
Буздәк районы, Урзайбаш авылы.

Бакчачы почмагы

# Мартта бакчачы мәшәкатьләре

**Бакчачы өчен иң җаваплы һәм мәшәкатьле айларның берсе ул март ае. Бу чорда үсентеләрне игътибар белән тәрбияләргә, аеруча җимеш агачларын сакларга киңәш ителә: чагу кояш нурларының кәүсәләргә зыян китерүе мөмкин.**

Ай башында кар астында калган ботакларны кар авырлыгыннан арындырырга онытмагыз. Чөнки эри башлагач, карның бозга әверелеп, аларны сындыруы мөмкин.

Берәр болытлы көнне, кәүсәгә һәм ботакларга кимерүчеләргә каршы куелган бәйләвечләрне алыгыз. Айның өченче декадасында (җылы көнне) алмагач, груша һәм "яшел коймаларны" кискәләп, формалаштыра башларга мөмкин.



## Җиләк-җимеш бакчасында



Ай ахырында, бакчадагы агачларда кышлаучы корткычлардан котылу чарарларын күрегез. Мәсәлән, 700 г. мочевинаны (карбамид) бер чиләк салкын суда эретеп сөзегез дә, бар бакчадагы агач-куакларга һәм ачылган туфракка сибеп чыгыгыз. Минераль ашламаның мондый көчле эремәсе корткычлар организмында тоз алмашын бозачак һәм аларны юк итәчәк. Март аенда үткәрелгән мондый эшкәртү берниндидә зыян китерә алмаячак. Мочевина урынына хәтта гадәти аш тозы кулланырга да мөмкин (10 литр суга 1 кг. аш тозы).

Әгәр агач кәүсәләре лишайниклардан зыянлаган икән, аларны кәүсәдә сут агышы башланганга кадәр 7—10 процентлы тимер купоросы эремәсе белән эшкәртергә киңәш ителә. Кәүсәләргә эремәне сиптерергә дә, пумала белән сөртергә дә мөмкин. 3 көн дә үтмәс, лишайниклар кәүсәдән үзләре үк кубып төшәр.

**Шунысын онытмагыз**: моны сут агышы башлангач эшләргә ярамый! Югыйсә, кайрыларны яндырып, агач һәм куакларга зур зыян китерүегез бар.

Бу айда бакчачының күзләре аеруча үткен булырга тиеш: җиләк-җимеш агач - куаклары һәм кышка күмеп калдырылган үсентеләр кимерүчеләр тарафыннан зур зыян күрмәгәнме, алар ничек кышлаган? Киселгән ботакларның кәрән-карачкыл төскә керүе — салкыннар зыян салган дигәнне аңлата.

Агач ботакларын игътибар белән тикшерү (лупа белән карау бигрәк тә отышлы) анда кышлаган зарарлы корткычларны һәм аларның йомыркаларын ачыкларга ярдәм итәр.

**Әгәр көздән эшләмәгән булсагыз, март ахырында җиләк куакларын иске һәм сынган ботаклардан арындырыгыз.**

Мартның беренче декадасында порей-суган һәм кара суган орлыгын бер җәйдә уңыш алу максатында утырталар. Порей-суганның Болгарский, Карантанский, кара суган орлыгының Одинцовец, Золотничок сортларына өстенлек бирегез.

Орлыкларны башта бер тәүлеккә суга салып тоталар, аннан юеш чүпрәккә төреп, бүрткәнгә кадәр тоталар. Әйткәндәй, утырту өчен 8-9 см. биеклектәге тартмалар алына. Рәт араларын 7 см. калдырып, 1-1,5 см. тирәнлеккә чәчегез. Орлыклар арасы 1 см. булырга тиеш.

Суны чама белән генә сибәргә киңәш ителә. Шытымнар күренгәннән соң тартманы төнлә 10-12, көндез 15-17 градус булган тәрәзә төбенә урнаштырыгыз. Болай иткәндә суган үсентеләре ачык туфракка утыртуны җиңелрәк кичерәчәк, ә аның кыяклары нык һәм матур яшел төстә булачак. Үсентеләрне җиргә утырткан вакытта аларның кыякларын һәм тамырларын яртылаш кисегез. Ачык туфракка апрель ахыры-май башында утыртырга мөмкин булачак.

## Борыч, помидор һәм баклажан утырту

Март башында биек булып үсүче помидор, шулай ук әгәр февральдә утыртмаган булсагыз, татлы борыч һәм баклажан орлыкларын утыртыгыз. Борыч орлыклары озак тишелә, шуңа да чыгышларын тизләтү өчен аларны ярты сәгатькә "Циркон" яки "Эпин-экстра" эремәсендә тотарга киңәш ителә (1 аш кашыгы суга 1 тамчы).



Туфракның температурасы 28-32 градус тәшкил итсә, борыч 8-10 көннән тишеләчәк. Ә баклажан һәм помидорлар 5-7нче көнне үк. Әгәр туфрак салкынрак булса, үрентеләр тишелү озакка сузылачак.

Шулай ук температураны 40-42 градустан артык җылытырга киңәш ителми, чөнки орлыкларның харап булуы мөмкин. 20 градустан түбәнрәк булса, борыч белән баклажан тишелеп тә тормаска, ә помидорның 15-17 көннән соң гына борынлавы мөмкин.

Шытымнар күренде икән, аларны чын яфраклар күренгәнне көтеп тормыйча, ашлама белән сыйлый башларга кирәк. Ашламаны суга кушып сибәргә киңәш ителә. Баклажаннар өчен **"Унифлор-рост"**, борыч һәм помидорлар өчен **"Унифлор-бутон"** препаратын куллану отышлы булачак. Шулай ук "**Аквадон-микро"**, яки чәчәкләр үстерү өчен тәгаенләнгән **"Идеал"** препаратларын да кулланырга мөмкин.

Әйткәндәй, шытымнарның яхшы уңыш бирүче үсенте булып җитешүе өчен яктылыкны да дөрес көйләү мөһим, югыйсә, үсеш ноктасында яфраклар урын алачак һәм чәчәк бөбәкләре барлыкка килү соңга калачак. Бу исә уңыш алу да соңрак срокка күчә дигән сүз.

Беренче чын яфрагы күренү белән, помидорны әле күчереп утыртканга кадәр, туфракны сыек кына бакыр эремәсе белән эшкәртергә киңәш ителә. Бу максатка "Хом" препаратын (бакыр хлорокисе) куллану уңайлы, чөнки ул салкын суда да эри һәм аны теләсә нинди савытта болгатырга мөмкин. Чәй кашыгының дүрттән бер өлеше "Хом" препаратын алабыз да (өеп түгел), шуны 3-4 литр суда эретәбез. Эремә озак вакыт саклана ала. Үсентеләргә аны 2 атнага бер тапкыр даими сибеп торыгыз. Болай иткәндә помидорларның фитофтороза дигән куркыныч чиргә каршы торучанлыгы артачак. Фитофторозага бик бирешеп бармасалар да, эремәне баклажаннарга да сибә аласыз, файдасы булачак. Борычлар бу чирне бар дип тә белми-белүен, тик бакыр эремәсе белән алар да рәхәтләнеп сыйланачак.

**Бакырны помидор, борыч һәм баклажан** өчен "Фитоспорин" эремәсе белән дә алыштырырга мөмкин (кечкенә ярмачыкны 3 литр суда эретәләр, эремә үтә күренмәле диярлек булырга тиеш).

Мартның өченче ункөнлегендә кыска буйлы помидорларны (50-70см. биеклектәге) ачык туфрак өчен утырталар. Урта полоса өчен: Белый налив, Скороспелый Сибирский, Дубок, Ритм, Лавина, Отрадный, гибридлардан Малышок орлыкларын утырту яхшы уңыш вәгъдә итә. Кыска буйлы помидорларны да биек булып үсүче сортлар кебек үк утыртырга мөмкин (февральдә дөнья күргән "Бакчачы почмагы"н карагыз).

Ай ахырында ак башлы кәбестәнең, шулай ук брюссель кәбестәсенең иртә өлгерүче сортларын утырталар. Тәҗрибәле бакчачылар ак кәбестәнең Гибрид трансфер, Июньская, Ранняя грибовская, Скороспелка сортларына өстенлек бирергә тәкъдим итә.

Чәчәр алдыннан орлыкларны башта 45-50 градус кызулыктагы суда җылыталар. Торф һәм гадәти туфрактан торган катнашманы тартмага 5 см. калынлыгында салалар. Рәт араларын 3 см. калдырып, орлыкларны 1 см. тирәнлектә чәчәләр. Орлык арасы бер-берсеннән 1-1,5 см. булырга тиеш. Орлыклар 4-5 көннән шытып чыгачак, аннан аларны якты урынга, төнлә температура 7-8, көндезләрен 10-12 градус җылылык булган урынга урнаштыралар. Шытып чыкканнан соң 12 көн үткәч, үсентеләрне размеры 8х8 см. булган савытка тирәнрәк итеп утырталар. Пикировкадан соң 2 тәүлек үткәч, үсентеләрне тагын чыныктыралар: +5 градус һәм югарырак булган урында тоталар.

25 марттан алып апрель урталарына кадәр уртача соң өлгерүче ак кәбестә сортлары, шулай ук чәчәкле, савой, кольраби, кызыл кучәнле кәбестә һәм брокколи утыртыла. Ак кәбестәнең Белорусская, Слава, Амагер, Московская поздняя, чәчәкле кәбестәнең Мовир, Отечественная, Гарантия сортларына игътибар итегез.

Ай буена февральдә чәчелгән татлы борыч, помидор һәм баклажан үсентеләрен даими тукландырып торырга онытмагыз. Ашламаның составы болай әзерләргә мөмкин: 3 литр суга 1 аш кашыгы суперфосфат, 1 чәй кашыгы нитрофоска.


## Чәчәк утыртыр вакыт

Ай ахырында астра һәм бәрхет гөлләренең орлыкларын утыртыгыз. Аларны 1,5 см. тирәнлектә туфракка чәчеп, су сибеп, өстен тигезләп, пленка белән каплап, җылы урынга урнаштырыгыз. Астрага күп чирләр яный, шуңа да ул утыртыласы туфракны алдан "Фитоспорин" эремәсе белән эшкәртергә онытмагыз. Үсентеләрне күчереп утырткан вакытта да яңа туфракны "Фитофторин" яки "Хом" препаратлары белән эшкәртегез.

Бу чорда гладиолус, суган, георгиннарны тагын бер кат тикшерегез. Барлык чирле өлешләрен сәламәт тукымаларга кадәр чистартып, киселгән урыннарны зеленка белән зарарсызландырыгыз һәм кабат саклауга салыгыз.

Чирле суганнарны ташлагыз, ә үсешкә кузгалганнарын яшел кыякызгы витаминнар алу өчен кулланыгыз. Тәрәзә төбенә утыртып куйсагыз, 1-2 атнадан сыйлана да башларсыз. Шулай ук яшел кыяк алу өчен сарымсакны да кулланырга була.

Гөлара АРСЛАНОВА.


Хикәя.

# Кычыткан арасында

Шешеп чыккан башын тотып Рәмзил кычыткан арасында утыра. Ул еламый, еларлык хәлдә түгел. Салкыннан бөрешкән бер йомгакка әйләнгән. Болай йомарлангач, эч, күкрәк бик нык өшеми кебек, ә менә арка тагын да ныграк туңа, салкын үпкәләрне чәнчи башлый. Шуңа түзми, Рәмзил судан чыккан эт кебек аратирә нык итеп калтыранып ала, авырту бер мизгелгә җибәргән кебек була. Ләкин, болай калтырану да арыта, ахры, алай кыланасы килми, бары тик йоклыйсы килә.

Малай үзе гаепле. Башсыз ул. Берәр иске куртка табып менә шунда чыгарып куярга дип, ничә тапкыр ниятләнде, ләкин эшләмәде. Бәлки, башкача тукмамаслар дип өметләнә дә тора. Шулай инде ничәнче кат алданды.

Аның әтисе улкадәр рәхимсез түгел, кулы белән генә суга, ә анисе өстәлдәге шешә белән алып орырга да мөмкин, утын белән тондыруы да бар. Кулына нәрсә якынрак, ала да суга, үзең аяу булмасаң, башыңны да ярып куяр. Чыгып качмый хәлең юк. Соңыннан малайны эзләп чыгалар. Тапсалар, туйганчы тукмыйлар инде. Шуңа да Рәмзил кычыткан арасында утыра, малайны моннан эзләргә өйдәгеләрнең башына да килгәне юк. Их, исерекләр күпме вакыт узганын сизми шул, ә салкын көздә кычыткан арасында ул бик акрын уза. Әнә, күктәге йолдызлар бүген аеруча якты, чөнки бүген салкын. Көз бит. Төнлә хәзер  җылы киемсез йөрерлек түгел. Ә малай киемсез. Ул инде калтыранмый да кебек. Тереме ул, әллә... Юк, тере сыман, ул уйлый әле, күз алдына китерә, әллә төшләнәме... Кем белсен. Туңып үлә язган, ягъни шушы малай кичергәнне кичергән кешеләр генә белә, ә тегеләр — өйдәгеләр— түгел. Бермәлне өн белән төш, фикер белән саташу бутала, үзеңнең инде тереме, әллә үлеме икәнеңне дә белмисең...

Их, мондый интегүләр өчен үч аласы иде. Ничек итеп? Аракыларына агу салып. Нинди агу? Ул кинода гына шкафтан алып бик җиңел генә агу эчерәләр, бездә андый нәрсә кайдан булсын. Йоклаган чакларында буаргамы әллә? Көч җитмәс, уянып китеп үзеңне асып куярлар. Ут төртергә! Менә монысы була торган эш, шырпы өйдә, бензин лапаста. Вәт шәп булачак, мин монда туңып үлеп барганда алар җылы өйдә, юрган астында ятсыннар әле. Рәмзил күз алдына китерә, юк, төшләнә шикелле: менә ул абзардан канистры белән бензин алып керә, аны никтер әтисе дә, әнисе дә күрми, ишетми. Менә малай өстәлгә сыгылып төшеп һаман да нәрсәдер мыгырдаган, чәйнәгән ата-анасын уратып идәнгә бензин агызып чыга. Тегеләр һаман да күрми, бензин исен дә тоймыйлар. Юк, алар моны күрергә тиешләр, алар аңларга тиеш. "Улым, нишлисең, яндырма безне, үтермә, зинһар, без синә моннан соң тимәбез. Син безнең улыбыз бит!" — дип әйтергә тиешләр. Ләкин алай әйтүче юк, күзен ачып караучы юк. Үз сүзләрен үзләре аңламасалар да һаман да тиргәшкән булалар. Малай өлкәннәргә гаҗәпләнеп карап тора да, соңгы өметен көтә. Ләкин ул юк. Рәмзил шырпы сызып идәнгә ташлый.

Ду итеп ут кабына, ялкын телләре бии, түшәмгә җитәргә тырыша. Ут дәхшәтенә буйсынып тегеләр дә кузгала, селкенә башлады, ничектер көч табып аягүрә бастылар. Кая бәрелергә, ни эшләргә? Болар кайда ишек, кайда тәрәзә икәнен хәтерләми. Һәр тарафта ут, ялкын. Котылу әмәле юк. Менә шунда инде күзләр ачыла. Менә шунда инде чәчләр үрә тора, күптән кирәге булмаган зиһен кире кайта. "Үләбез! Янып үләбез!" Зиһен шуны аңлый. Йөрәкне коточкыч курку биләп ала, чөнки тере килеш яну тәмук җәзасы бит ул. Менә шунда инде чәбәләнү, үкерү башлана.

Рәмзил боларны күрә, тик, ни гаҗәп, кузгалмый, бу якка чыгыгыз, ишек монда дип кычкырмый. Шатланмый да ул, үч алу теләге каядыр юкка чыккан. Ул битараф, ул гамьсез. Гүя аның әти-әнисе утта акырып янмый. Бермәлне хәтта кызык булып китте — алар нәрсә дип акыра соң? Тавышлар күмәк икән, шау-шу арасыннан: "Су", "Монда сип", "Анда кермә!" — дигән сүзләр аңлашылып кала. Нигә кычкыралар соң алар, күзләрен акайтып нигә бәргәләнәләр? Өй януы бер дә куркыныч түгел икән бит. Рәмзилнең үзенә бер дә кыен түгел, киресенчә, ул җылына башлады, аңа рәхәт булып китте, барысы да әйбәт, бөтен тәне буйлап җылы тарала. Ул җылылык иркә генә итеп малайны чолгап ала, күзләрен йомдыра, аңын томалый.

Бер гаиләдән өч кеше дәваханәгә барып керде. Ир белән хатын утта пешкән, ә балалары туңган иде. Менә гаҗәп.

Ярый әле кешеләр сизеп калган. Ут эченнән ир белән хатынны алып чыкканнар. Алар инде төтенгә чәчәп һушсыз була. Янгын сүндерүче машина килгәнче өй янып та бетә. Ә малай кайда? Бахыркаең янып үлде микән? Хуҗаларны коткаручылар аптырауда, алар үзләрен гаепле саный, башлар иелгән. Ата-анасы белән маташканда нишләп баланы эзләмәдек икән? Ләкин алар белә, эзләрлек түгел иде, исерек хатынны сөйрәп чыгарганда үзләре чак янып үлмәде, яңадан керү мөмкин түгел иде. Шулай да бу аклану намусны бөтәйтми, халыкка хәзер ни дип әйтәсең, йөрәкне кара авырлык басты.

Төнлә килми калган кешеләр бүген килеп туздырылган бүрәнәләргә карап көрсенә, арлы-бирле йөренә, баш чайкыйлар. Шул эчкечелек аркасында баланы харап иттеләр, үзләре дә йортсыз калды, дип уйлыйлар. Шунда берсе кычыткан арасында бөгәрләнеп каткан малайга килеп юлыкты. Тәне суык булса да, сизелер-сизелмәс кенә сулышы бар иде әле малайның.

Көннәр үтте, каза күрүчеләр терелә башлады. Иң авыры Рәмзилгә иде, аның ике үпкәсе дә нык шешкән булып чыкты. Сөйләшерлек хәлгә килгәч, ул следовательгә өйгә ничек ут төрткәнен сөйләп бирде.

Беренче булып дәваханәдән бир кеше чыкты. Бик озак басып торды ул торымбашларга карап. Нишләргә соң, күзгә каршы йортсыз торып кал әле? Их, Рәмзил, Рәмзил, эшләдең син безне, нигә шулай иттең инде.

Соңыннан, бераз тынычлана төшкәч, ир шуңа игътибар итте. Малай следовательгә әти белән әнине уратып-уратып бензин сиптем, дип сөйләгән. Шуннан аларның янганын карап тордым дигән. Димәк, канистр янгында, өй эчендә калган булырга тиеш, ә ул урынында тора һәм бензины да кимемәгән. Ничек була инде бу? Рәмзил дөресен сөйләмәгәнме әллә? Алайса, кем ут салган? Галимнәрдә зиһен асты, тирәнтен хәтер дигән төшенчә бар, әллә шул дөрес микән? Менә бит, ир лаякын исерек иде, берни исләрлек хәлдә түгел. Аз гына акылларында булсалар уттан үзләре чыгарлар иде бит. Юк, аек акылда түгел иде алар, берни исләрлек хәлдә түгел иделәр. Шулай да, йөри торгач, нәрсәдер исенә төшә башлады бит. Алар ялгыш аракы стаканын аударды, хатынының исерек чагында селтәнеп сөйләнә торган гадәте бар, ул шулай селтәнеп шешәне дә бәреп төшерде әле. Анысы аракысын агызып тәгәрәп китте. Шуның өчен гаилә башлыгы үзенең җанашына кизәнеп тә алды шикелле. Шулай, менә бит, шунысына кадәр искә төште. Икәүләп тәмәке тартып утырдылар. Аракы ул бензин белән бер бит инде, бер чаткы җитә... Ах, болай булгач малай гаепсез булып чыгамыни? Шулай шул. Мондый уйдан ирнең күңеле җиңеләеп киткәндәй булды. Малай гаепсез икән бит! Алайса, ул нигә шулай сөйли? Менә шушы сорауга җавап уйлаудан ирнең тагы да маңгае җыерылды. Әгәр шулай сөйли икән, димәк, ул безнең янып үлүебезне теләгән! Менә кайда хикмәт. Их, улым, улым, без сиңа шул тиклем дә дошманмыни, безне шул кадәр дә күрәлмисеңмени?

Ир кеше ачулы уйлар кичерсә дә, Рәмзилне беренче тапкыр улым дип атады.

**Заһит МУРСИЕВ.**



## Шүрәлеләр дөньясы

Чит җирләрдә йөргәндә
Кем генә безгә карый.
Күңелләрне бушатырга
Шайтан булса да ярый.

Менә шулай бер заманны
Каунас урамында
Җен музее тәрәзәннән
Шүрәле карап тора.

Әй, якташым, исәнме, дим,
Нинди җилләр ташлады?
Таныш эзләп йөри торгач,
Аякларым калмады.

Әйдә, кайтыйк, шүрәле, дим,
Калганнарын сөйләшербез
Туган якларга кайткач.

"Кайтыр идем, тик оялам
Тукайның гайбәтеннән.
Җир астына качар идем
Былтырның хәйләсеннән.


Дәшмәскә бит, шул Тукайга,
Күрмәскә һәр тишекне.
Бар дөньяда төшерде бит
Минем авторитетны".

Син курыкма,
Шүрәлекәй,
Заманалар үзгәрде.
Хәзер инде ун кешенең
Үзенә бер шүрәле.

Килеп төштек тимер кошта
Шүрәле белән бергә.
Белсәгезче, якташларым,
Шундый рәхәт күңелгә.

И туган Җир ,
и газиз ил,
шүрәлеләр
дөньясы...

**Варис АКБАШЕВ.**




# Булачак табиблар өчәр ел лекцияләргә йөрмәгән

**Аларны “лайк” аша тапканнар... Башкорт дәүләт медицина университеты студентлары үзләре урынына дәрескә икенче кешеләрне җибәргән. Моның өчен алар социаль челтәрләрдә махсус төркем булдырганнар. Бу аферада катнашучыларны шундый игъланнарга "лайк" куючылар аша ачыклаганнар.**

Лекцияләргә йөрмәгәнне сизмәсеннәр өчен, "Синең өчен БДМУга барып кайтам" дигән төркемгә кереп, акчага дәрескә йөрергә риза булган кешене табарга кирәк. Бу схема ике якка да файдалы: студентлар дәрес “калдырмый", буш вакытлары да күп, деканатка "студентлар йөри" дип отчет бирү өчен дә әйбәт.

Бу хәл өч ел дәвам иткән, тик Адель исемле бер студентның эзенә төшкәч кенә вакыйгага нокта куелган. Ул үзенә алмашчы табып, Бали утравына кояшта кызынырга киткән. Бу алдашуда катнашкан барлык студентлар да университеттан куылган. Деканат бу хәлне белгәч, эзәрлекли башлаган. Социаль челтәрләрдә аноним постлар язучыларны һәм үзләренә алмаш эзләүчеләрне табу мөмкин түгел, әлбәттә. Әмма андыйларга ярдәм итәргә әзер булучылар күренеп тора, алар беркемнән дә яшеренми. Игъланнарга "лайк" куючы кешеләр белән әңгәмәләшкәч, чын студентларны табып, чакыртканнар. Ләкин алар укуларын дәвам итү өчен түгел, ә документларын алу өчен килгәннәр.



# Аз гына көтәсе килмәгән

**Сибайда яшәүче хатын баласын озак кабул иткәнгә күрә табиб-педиатрга ташланган. Ана кеше баласы белән поликлиникага килеп, җәнҗалларсыз чират торып, табиб кабинетына кергән.**

Әмма кабул итә башлар алдыннан педиатр, коллегалары белән киңәшмәгә сылтанып, аз гына көтеп торуны үтенгән. Табиб берничә минутка кабинетыннан чыккан.

Белгечнең кабинетка кире керүе булган, чыгырыннан чыккан ана аңа йодрык төйнәп ташланган. Соңрак ул табибны поликлиника буйлап куып йөрткән. Педиатрны башка хезмәткәрләр яклап чыккан. Низагчы хатын өстеннән полициягә гариза язганнар.




# Сәер корпоратив

**Тверь өлкәсендә түрә хатыннарның сәер корпоративы турында ишеттегезме әле?**

“Подъем" порталы язуынча, стриптиз ясаучы чакырылган бу корпоратив Сонковский округы хакимиятендә булган. Кадрлардан күренүенчә, кабинетта киңәшмәләр өчен өстәл тирәли хатын-кызлар тезелешеп утырган. Шулчак Том Джонсның «Sex Bomb» җырына селкенгәләп, гаурәтләрен яшермәгән ялангач ир-ат костюмындагы (ягъни биюче үзе ялангач түгел, ул шәрә ир ат костюмы кигән) кеше керә. Ул хатын-кызлар алдыннан бии-бии үтә. Түрә хатыннар көлә, кул чаба. Кадр артында 8 март корпоративында катнашкан бер ирнең “Тарзан пришел к вам" дигән сүзләре ишетелә.

Корпоративны хакимияттә эшләүче Юрий Байков оештырган. Төбәкнең Сонковский муниципаль округы башлыгы Андрей Гусев сүзләренчә, хакимияттә “ужас булган" һәм бәйрәм өчен җаваплы чиновникны ул эштән алган.

“Чараны оештыру беренче урынбасарга йөкләтелгән иде. Һәм менә шундый коточкыч хәл булган. Стриптиз биюче — рәсми фирмадан, былтыр да шушы фирмага мөрәҗәгать иткән идек. Беренче урынбасардан моны сорадым мин, әлбәттә, аны эштән җибәрдем. Мәсьәләне ачыклыйбыз", — дип хәбәр итте округ башлыгы.

Миңа калса, бу — оятсызлык билгесе. Эш урынында шундый тәртипсезлекләр оештыру башка сыймый...



# Депутатлыктан да теләп китәрләр икән...

**Чиләбе өлкәсеннән 25 яшьлек депутат Максим Гулин Дәүләт Думасыннан китәргә булган. “Яңа кешеләр” партиясе вәкиленең вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылу карары проекты махсус сайтта бастырылган.**

Документка ярашлы, Гулинның вәкаләтләре 13нче марттан туктатылган дип исәпләнә. Карар парламентның түбәнге палатасының пленар утырышында 16 мартта тикшереләчәк.

РБК каналы белән әңгәмәсендә депутат Мәскәүдә эшләргә планлаштыруын әйткән. Яңа эш урыны турында соңрак хәбәр итәм, дигән ул.

“Яңа кешеләр" партиясе матбугат хезмәтендә исә Гулин эштән үз теләге белән китү турындагы гаризасын түбәнге палата рәисе Вячеслав Володинга 10 мартта ук юнәлткән иде, диләр. “Максим Гулин Дәүләт Думасында эшләгән башлангычларын башкарма властьта гамәлгә ашырырга җыена", — диелә ул хәбәрдә.

Мине бер генә нәрсә гаҗәпләндерә: депутатлыктан кем китә инде, ә? Шундый әйбәт һәм җайлы эш урыны...

# Автобуска кереп өлгермәгән

**Түбәнге Тагилда 73 яшьлек пенсионер автобуска эләгеп калган да, аңа тагылып аркасында 20 метрлап ара үткән. Автобусның пенсионерны юлдан сөйрәвен тасвирлаучы видео социаль челтәрдә таралган.**

Бу хәл 10 март кичендә булган. Узып баручы машина видеорегистраторы кадрларында тукталыштан кузгалып китүче автобус күренә. Өлкән яшьтәге ир салонга кереп бетеп өлгерми, аягы автобус ишегенә кысылып кала. Пенсионер юлга егыла, автобус аны пычрак юлдан 20 метрлап сөйрәп бара.



Автобус туктагач, водитель “кулларын болгый- болгый чыгып йөгерде дә, кире утырып китте" дигәннәр социаль челтәрдә. Шаһитларның берсе сүзләренчә, салондагы пассажирлар кычкыра башлагач кына водитель транспорт чарасын туктаткан.

Соңрак пенсионер әллә ни каза күрмәгән, нибары сыдырылган гына, дип хәбәр иткәннәр.



# Тәрбияче хатын явызлыгы

**Курган өлкәсенең Катай балалар йортында эшләүче тәрбияче бер сабыйны чәчләреннән сөйрәп йөрткән. Балигъ булмаган кыз баланы мәсхәрәләү видеога эләккән.**

Социаль челтәрләрдә таралган видеороликта балалар йорты хезмәткәренең тәрбияләнүчене чәченнән эләктереп кроватька атып бәрүе күренә. Бу вакытта бүлмәдә тагын бер бала булган.

Курган өлкәсе хөкүмәтендә тәрбиячене эштән җибәрүләрен сөйлиләр. “Аңа карата хокук саклау органнары тикшерү алды эше оештырган. Әле балалар йортына социаль блок өчен җаваплы чиновниклар җыелган", — диләр алар. Төбәк губернаторы Вадим Шумковка да бу вакыйга турында хәбәр иткәннәр.


Бу хәлгә кадәр тәрбияче үз эшендә кисәтүләр, шелтәләр алмаган. Эчү белән мавыкмаган. Полиция хезмәткәрләре тәрбиячене бу хәлгә нәрсә этәрә алды дигән сорауга җавап эзли.

Каза күргән кызны табиблар караган, тәнендә җитди җәрәхәтләр ачыкланмаган. Аның белән психологлар эшли башлаган.

Шундый вәхшиләр ник балалар белән эшли икән?

Әлфия ШАКИРҖАНОВА әзерләде.

# Үзегезне беләсезме?



**Әгәр сез бәхәсләрдә еш җиңеләсез икән, димәк сез…**

Артык үсешкән интеллектлы кеше. Һәм теләсә-нинди мәгълүматны анализлый аласыз. Бәхәс вакытында сез переоценка үткәрәсез, бөтен аспектлар да сезнең тарафтан җитәрлек өйрәнелмәгән дип шикләнә башлыйсыз. Интеллект ягыннан саерак кеше мондый анализ эшләп тормый һәм үз-үзенә артык ышануы аркасында үзенең ялгыш фикерен дә хакыйкәткә чыгара.

**Әгәр сез тәнкыйтьне авыр кабул итәсез икән, димәк...**

Сез үз-үзенә ышанмый торган кеше. Тәнкыйть сезнең өчен хуплаудан мөһимрәк. Чөнки ул сез үз-үзегезгә язган җитешсезлекләрне дәлилли. Гамәлләрегезнең тискәре бәяләмәсен баш мие куркыныч янаучы хәл итеп кабул итә, шуңа да кортизол гармоны бүлеп чыгара башлый.

**Әгәр төшегездә көндез эшләгән эшләрегезне күрәсез икән, димәк...**

Күп вакытыгызны бер төрле эш башкарып үткәрәсез. Моны баш мие өйрәнү-уку сигнал дип кабул итә һәм йокы вакытында белемне эшкәртеп, көндез алынган тәҗрибәне ныгытып куярга тырыша.

**Әгәр сезнең язуыгыз ямьсез икән, димәк...**

Сезнең баш миегез кулыгызга караганда кызурак эшли. Уйлау тизлегегез матурлап язып торырга вакыт бирми.

**Әгәр сез берәр начар гадәттән котыла алмыйсыз икән, димәк...**

Сез артык ялкау кеше. Әлеге гадәт ярдәмендә сезнең баш миегез ял итәргә яки мөмкин кадәр азрак көч сарыф итеп эшләргә тырыша.Ниндидер өйрәнелгән хәрәкәтләрне кабатлау өчен энергия азрак кирәк. Теләсә нинди кабатлана торган эшне баш мие гадәткә әйләндерергә тырыша.


**Әгәр ашыкканда күз алдында яткан әйберне таба алмыйсыз икән, димәк...**

Сез уйлаганга караганда тизрәк күрәсез һәм сезнең баш мие күзләр җибәргән мәгълүматны эшкәртеп өлгерә алмый. Бу нерв киеренкелегенә бәйле.

**Әгәр сез ни өчен килгәнегезне яки нәрсә эшләргә җыенганыгызны онытасыз икән, димәк...**

Сез үзегез дә сизмәстән бөтенләй башка нәрсәгә бәйле проблеманы уйлап йөрисез. Баш мие берничә мәсьәләне хәл итү белән мәшгуль икән, "сбой" була һәм бер мәгълүмат икенчесен кысрыклап чыгара. Чөнки кыска вакытлы хәтер күләме бик аз.

# СКАНВОРД




Марат ГОБӘЙДУЛЛИН. Казан шәһәре.

Вәли балалар бакчасына җыена.

— Әни, мин кечә балалар бакчасында саф һавага чыккач, кар ашадым. Хәзер минем тамагым авырта...




Әнисе балалар бакчасына йөгерә. Тәрбиячене эзләп таба.

— Мин Сезнең белән җитди рәвештә сөйләшергә килдем!

— Бик яхшы. Минем дә Сезнең белән җитди сөйләшәсем бар.

— Нишләп Сез тышта йөргәндә балаларның кар ашаганын күрмисез?

— Кем кар ашаган? Вәлиме? Юк, ул кичә көндез саф һавага чыкмады бит.

— Ничек чыкмады? Ник?

— Чөнки алдагы көндә Сез аңа сыра салып биргәнсез һәм аның чатнап башы авырта иде...

***

Әгәр җитәкчегез сезгә карата яхшы мөнәсәбәттә икән, димәк сезгә тиешле акчаның би-ик күбен түләп бетермиләр...

***

— Сөеклем, шатлык! Мин "права" алдым. Хәзер машина кирәк! Ниндине алырга икән?

— Кер юа торганы иң шәбе булыр!

**Эльмира ИБРАҺИМОВА әзерләде.**

## 10нчы сандагы сканворд җаваплары:

**Горизонталь буенча**: кола, ятма, парча, бина, Тула, салат, күке, сыер, Арно, йокы, бар, да, умка, лайм, Ааре, кендек, НКВД.

**Вертикаль буенча**: каймак, атау, лак, куян, каба, ерым, "Баек", Апас, Сарман, Арал, ыр, Кай, аренда, факт, Роальд.


**Редакция газеты "Омет" Республиканского информационного центра – филиала ГУП Республики Башкортостан "Издательский дом "Республика Башкортостан"**

**Учредитель: Агентство по печати и средствам массовой информации Республики Башкортостан, Государственное унитарное предприятие Республики Башкортостан Издательский дом "Республика Башкортостан"**

**Адрес издателя: ГУП Республики Башкортостан Издательский дом "Республика Башкортостан". 450079, Республика Башкортостан, г.Уфа, ул. 50-летия Октября, 13**

**Издается с 12 июля 1991 года.**

**Выходит в пятницу на татарском языке.**

**Баш мөхәррир Рәдис Гыйльван улы НОГМАНОВ.**

Мөхәрририят:
Гүзәл ГАЯНОВА (баш мөхәррир урынбасары),
Рөстәм ХӘНӘФИН (җаваплы секретарь),
Рәдиф ФӘТКУЛЛИН,
Гөлара АРСЛАНОВА.

Газит редакциясенең адресы: 450079. Башкортстан Республикасы, Уфа, Октябрьнең 50 еллыгы урамы, 13 (9 кат).

**РЕДАКЦИЯ ТЕЛЕФОННАРЫ:**

баш мөхәррир – 8(347) 273-94-38;

баш мөхәррир урынбасары – 8(347) 273-94-56;

сәясәт, хатлар, «Сихәт» – 8(347) 273-98-27;

социаль проблемалар, дин, «Чаткылар», әдәбият-сәнгать – 8(347) 273-97-89;

спорт, фотохәбәрче 8(347) 273-95-67;

бухгалтерия – 8(347) 273-43-43;

реклама 8(347) 273-64-81, +79273323582.

❑ Газета отпечатана в Республиканском издательстве "Башкортостан" — филиале ГУП Республика Башкортостан Издательский дом "Республика Башкортостан". 450079, Республика Башкортостан, г. Уфа, ул. 50 лет Октября, 13

❑ Индексы: на текущий период и досрочная подписка на 2023 год — П2768, 50617 — подписка на сайте rbsmi.ru.

❑ Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

❑ Гәзиттә язмалары басылган авторларның фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Игъланнарның эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

**Тираж – 9979.**

❑ Материалларны күчереп басканда "Өмет" гәзитен күрсәтү мотлак.

❑ Реклама, белдерүләр, котлаулар бирергә теләүче гәзит укучыларыбыз игътибарына:

❑ Акчаны түбәндәге исәпкә күчерергә мөмкин: Филиал ПАО "БАНК УРАЛСИБ" г.Уфа , р/с 40602810200000000009, БИК 048073770, кор./счет 30101810600000000770.

❑ Квитанция белән текстыгызны редакциягә түбәндә күрсәтелгән адрес белән җибәрүегез сорала. Котлау хакы — 950 сум, фото белән 1000 сум.

❑ Гәзит Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтү буенча федераль хезмәттә 2017 елның 2 маенда ПИ №ФС77-69582нче номерлы таныклык белән теркәлде. Гәзит Башкортстан Республикасының "Республика Башкортостан" Нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесе филиалы — "Башкортостан" республика нәшриятында басылды.
Адрес: Башкортстан Республикасы, Уфа-79, Октябрьнең 50 еллыгы исемендәге урам, 13. Тел. 22-88-73.

❑ «Өмет» гәзите редакциясе эшчәнлегенә карата фикерләрегезне һәм тәкъдимнәрегезне WWW.pressarb.ru сайтына җибәрә аласыз. Шушы ук сайтта агентлык эшчәнлегендәге яңалыклар, вакансияләр, приказлар, үткәрелүче чаралар белән танышырга һәм аларга карата фикерләрегезне һәм тәкъдимнәрегезне белдерергә мөмкин.

**Кул куелу вакыты: 16.00** **Кул куелды: 14.30.**

**Дежур: Г. АРСЛАНОВА, А. ГӘРӘЕВА.** **Заказ: 340.**


podpiska.pochta.ru




# Белмәсәң – бел!

**Март аенда һава температурасы 5 градустан югары күтәрелгәч, санитар кисү башкарыла. Агачның төбен калдырмыйча тигез итеп кисәргә киңәш ителә. Черетә торган микрофлора үтеп кермәсен өчен киселгән урыннарга гына түгел, агач кабыгындагы яраларга да бакча сумаласы сөртеп куярга кирәк.**

Сумаланы дөрес сайлау мөһим. "Вар Сад Пчелка" - ышанычлы, тулысынча табигый сумала. Ул бал корты балавызыннан, ылыс сагызыннан, ак чыршы һәм үсемлек майларыннан, шулай ук үсемлекне саклый торган Фитоспорин фитобактерияләреннән тора. Бу сумала агач яраларын каплап кына калмый, ә дәвалый да. Моны агач һәм куакларда сут кузгалганчы эшләп калырга кирәк.

Мартның җылы бер көнендә агачларны тагын аклап чыгарга кирәк. "Доктор сад" дигән ак бакча буявын сайларга киңәш итә белгечләр. Ул дәвалау функциясенә дә ия, чөнки табигый эликсирлар һәм файдалы фитобактерияләр кушылган.

Карлыган белән крыжовник куакларын да язгы кисү чоры җитте. Кара карлыганның картайган ботакларын утыртылганнан алып бишенче елдан кисә башлыйлар. Ә кызыл, ак карлыган белән крыжовникның карт ботакларын 6-8 яшькә җиткәч кенә кисеп ташлыйлар. Куакларны шулай яшәртеп алу уңышны бермә-бер арттыра. Кара карлыган куакларын игътибар белән карап чыгыгыз: кабарып торган юан бөреләр (бөре талпаны) юкмы? Булса, җыеп яндырырга кирәк. Агачларга ябештергеч билбаулар куеп чыгыгыз. Ул алмагачны, мәсәлән, алма коңгызыннан һәм озынборын коңгызыннан әйбәт саклый. Җимеш агачларына, куакларга ялгау өчен чыбыклар әзерләргә вакыт. Карлыган чыбыкларын кисеп алып, сулы савытка куеп, тамыр җибәргәч, туфраклы савытка утыртыгыз. Бакчада җир җылынгач, билгеләнгән урынга күчерегез. Көзгә менә дигән куак булып үсеп җитәр.

# Ипи яратасызмы?



Ипине чамадан тыш күп ашаучыларда серотонин гормоны "тәртиптә" булмаска мөмкин. Серотонин — ул бәхет гормоны.

Серотонин җитешмәгәндә, кеше, үзе дә сизмәстән, икмәк һәм башка крахмаллы азыкларны күп куллана башлый.

Ипи ашау теләген киметү өчен табигый дару - L-триптофан эчеп карарга була. Ул сәламәт туклану кибетләрендә сатыла.

L-триптофан серотонинга әверелә. Аны йокы алдыннан эчү яхшырак. Серотонин йоклап китәргә ярдәм итә һәм яхшы йоклата.

Шулай ук, ул икмәк кенә түгел, шоколад ашау теләген бетерә, депрессияне киметә.

# Әбиләр исе

**ИСӘПКӘ АЛГАНЫГЫЗ БАРДЫР, ОЛЫ ЯШЬТӘГЕ ӘБИ-БАБАЙЛАРДА ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ИС БУЛА. ЮК, ЮЫНМЫЙЧА ЙӨРГӘН ЯКИ БЕРӘР ТӨРЛЕ АВЫРУЫ БУЛГАН КЕШЕЛӘР ТУРЫНДА СҮЗ БАРМЫЙ. ТАЗА, САУ-СӘЛАМӘТЛӘР ТУРЫНДА. ЧЫНЛЫКТА, ОЛЫ КЕШЕНЕҢ ИСЕ 2-НОНЕНАЛЬ ДИП АТАЛГАН БИЛГЕЛЕ БЕР ХИМИК МАТДӘГӘ ИЯ. БУ ХИМИК МАТДӘ КЕШЕ ТИРЕСЕНДӘГЕ ОМЕГА-7 МАЙ КИСЛОТАСЫ ТАРКАЛЫП БЕТКӘЧ БАРЛЫККА КИЛӘ. МОНДЫЙ ИС ҖИҺАЗЛАРГА, КИЕМНӘРГӘ, ӘЙБЕРЛӘРГӘ, КИТАПЛАРГА ДА СЕҢӘ. КАРТАЙГАЧ, МОНДЫЙ ИС КИЛМӘСЕН ӨЧЕН НИШЛӘРГӘ?**

## Су эчәргә

Тиешле күләмдә су эчү табигый рәвештә килеп чыгучы матдәләрне, исләрне вакытында "юарга" мөмкинлек бирә. Көненә, әкренләп, 2 литр чамасы су эчәргә кирәк.



## Юынырга

Ешрак су коенырга. Өйләрендә душ, ванна булганнарга бу уңайлы, әлбәттә. Олы кешеләр көн саен берәр кабат булса да душта коенса, тәннәреннән ис килү кими. Сәламәтлек өчен бу бигрәк тә файдалы. Әгәр дә бу кагыйдәне санга сукмый башлыйсың икән, 2-ноненаль ныграк бүленеп чыга һәм истән котылып булмаячак.

## Киемне алыштырырга

Эчке киемне көн дә алыштырып торырга кирәк. Картлар исе чүпрәккә тиз һәм нык сеңә.

## Бүлмәне җилләтергә

Бу процедура исне бетерү өчен генә түгел, сәламәтлек өчен дә файдалы.

**Ләйсән КАСПРАНОВА.**

"Өмет" аша котлагыз!

Әти-әниләрегезне, туганнарыгызны, дусларыгызны туган көннәре, юбилейлары уңаеннан "Өмет" газете аша котлый аласыз. Бәйрәм бүләге итеп алар турында җылы эчтәлекле язмаларыгызны, чагу сурәтләмәләрегезне безгә электрон почта яки ватсап аша җибәрегез. Котлау язмаларын редакциябез журналистлары да әзерләп бирә ала.

Белешмә өчен телефон:
8-927-33-23-582.

Мәхәббәтем, кайда син?

Әле сез һаман ялгызмы? Мәхәббәтегезне очратып, бәхетле гаилә кору турында хыялланасызмы?



ТАНЫШУ ТУРЫНДА ИГЪЛАН ЯЗЫП, БЕЗГӘ ВАТСАП АША ҖИБӘРЕГЕЗ! "ӨМЕТ"НЕ РЕСПУБЛИКАНЫҢ ТӨРЛЕ ПОЧМАКЛАРЫНДА АЛДЫРАЛАР, НАСЫЙП ЯРЫГЫЗ КҮРЕП ШАЛТЫРАТЫР.

Игълан бирү өчен
Тел:. 8-9273323582.

Племптицефабрика
ООО "Асяновское"
реализует:
-бройлеры суточные "Росс-308" - 20, 28 марта, 4 апреля
- подращенные бройлеры (с 21 марта)
- инкубационные гусиные яйца
- комбикорм "Стартер"

Адрес:
Дюртюлинский район, с. Асяново
Тел.: 8-34787-66-5-38,
8-929-755-20-55,
8-927-321-83-70.
Работаем без выходных!
Реклама

ООО «Либерти»
Вахтовый метод!
✓ЭЛЕКТРОГАЗОСВАРЩИКИ
✓МОНТАЖНИКИ
✓УПАКОВЩИЦЫ (КИ)
✓ДОРОЖНЫЕ РАБОЧИЕ
✓ПОДСОБНЫЕ РАБОЧИЕ
ОГРН 1151832018910.
Бесплатное проживание, стабильная з/п, оформление по ТК РФ
8 987 14 08 473 Эльмира
e-mail: Liberty102@bk.ru
Реклама